СИҢА ДА, МИҢА ДА
Яңа елдан QR-кодны антитәнчекләргә карап бирәчәкләр
> 2

КУРКЫНЫЧ КЫШ:
елгаларда боз ышанычлы түгел
> 2

НОМЕРДА – ДОКУМЕНТ
Татарстан Президенты имзалаган яңа законнар
> 3–6

УКУЧЫ СҮЗЕ
«ВТ» укучылары хатларында – тормыш кыйпылчыклары
> 9

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 182 (28764) | Сишәмбе | 14 декабрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

ЙӨТКЕРҮ ТӨЧКЕРҮ ГЕНӘ ТҮГЕЛ

РЕСПУБЛИКАДА 39 МЕҢНӘН АРТЫК УКУЧЫ МӘКТӘПКӘ БАРМЫЙ

Республикада ОРВИ белән авыручы балалар саны 2,5 тапкыр арткан. Ютәлле икән, балаңны бакчага, мәктәпкә җибәрмә! Табиблар әти-әниләргә әнә шулай дип киңәш итә. Татарстанда 300дән артык сыйныф карантинга ябылган. Коронавирус та беркая да китмәде, әлеге чир илдә 53 мәктәпне онлайн укуга күчәргә мәҗбүр иткән. «ВТ» хәбәрчесе бакча һәм мәктәпләрдәге вазгыятьне белеште.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Татарстанда онлайн укуга күчәргә җыенмыйлар. Республиканың Мәгариф һәм фән министрлыгында әнә шулай диделәр. Ник дигәндә, кайбер төбәкләрдә хәлләр катлауланып, укучыларга өйдә торып укырга туры килә. Псковта, мәсәлән, ОРВИ һәм грипп аркасында башта һәр биш сыйныфның берсен карантинга япканнар. Авыру балалар саны арткач, мәктәпкә баруны бөтенләй туктатып торырга туры килгән.

Декабрь башында узган матбугат очрашуында Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе башлыгы урынбасары Любовь Авдонина республикада 11562 укучының карантинда булуын әйткән иде. Бу – 466 сыйныф дигән сүз. Болар – Әлмәт, Казан, Чаллы шәһәрләре, Биектау, Баулы, Мамадыш, Минзәлә, Сарман, Тукай, Чистай районы укучылары. Авыручыларны сәламәт балалардан аерып тору чирнең таралуын киметүдә нәтиҗәле ысул булып санала.

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының матбугат үзәгеннән яңа саннарны белештек. 10 декабрьгә китерелгән мәгълүматларга караганда, карантиндагы сыйныфлар саны – 307. Салкын тидергән, грипп йоктырган 39040 бала мәктәпкә йөрми. Тулысынча читтән торып укуга күчкән мәктәпләр юк.

Арча районындагы 1 нче мәктәптә укучы 700дән артык баланың нибары 200е генә укырга йөри, дигән хәбәрне ишетеп, аптырап шалтыраткан идек.

– Бездә 748 бала укый. Бүген 64е авырый. Карантинга ябылган сыйныфлар юк. Иң күп дигәндә, сыйныфта 7 укучының килмичә калганы бар. Әгәр авыру билгеләре бар икән, үзебез үк килмәскә кушабыз. Иртән температураларын тикшерәбез. Йөткергән очракта да кире борабыз. Сыйныфларда балалар күчеп йөрми, тәнәфес вакытында сыйныфларны җилләтәбез. Бактерицид лампалар куелган. Исән-сау гына булсыннар, безнең өчен һәр бала кадерле, – диде мәктәп директоры Эльмира Сафина, имеш-мимешләрне кире кагып.

Арча районы хастаханәсе баш табибы Рифат Идрисов ноябрь ае белән чагыштырганда хастаханәгә ОРВИ белән мөрәҗәгать итүче балалар саны 1,5–2 тапкыр артуын әйтте. «Грипп белән авыручылар аз. Салкын тиеп, өйгә чакыручылар да, сырхауханәгә килүчеләр дә күбәйде. Коронавирус белән авыручылар да бар», – диде баш табиб.

Баулы районының мәгариф бүлеге башлыгы Дәринә Ганиева әйтүенчә, аларда укучыларның 13 проценты ОРВИ белән авырый.

– Мәктәпләрдә барлыгы сигез сыйныф карантинга ябылды. Гадәттә, биш көнгә ябабыз. Бүген карантин бетәргә тиеш иде инде. Коронавирус белән авыручы балалар юк. Укытучыларның 97 проценты прививка ясатты, калганнарының медицина белешмәләре бар. Берничә укытучы гына вакцина ясатудан баш тартты. Мәктәпләрдә һава рециркуляторлары куелган. Иртән балаларның температураларын тикшереп кертәбез, дезинфекция чаралары уздырабыз, – диде Дәринә Ганиева.

Республика балалар клиник хастаханәсенең матбугат үзәгеннән алынган мәгълүматларга караганда, ике атна эчендә ОРВИ һәм салкын тию (йөткерү, борыннан агу) кебек авырулар белән аларга 1600 кеше мөрәҗәгать иткән.

Казанда шәфкать туташы булып эшләүче Гөлия Хәсәнова өч яшьлек кызы белән өйдә утырырга мәҗбүр.

– Азалия ике атнадан бирле салкын тиеп авырый инде. Башта температурасы булмады. Борыныннан акты, йөткерде. Берничә көн инде температурасы төшми, тамагы кып-кызыл. Балабызны октябрьдә бакчага биргән идек. Анда җайлашканда бераз чирләп алды. ИялӘште дигәндә, тагын авырый башлады. Төркемдә дә авыручы сабыйлар бар. Педиатрны өйгә чакырган идек, авыручылар күп, кичкә генә килеп җитә алам, диде. Без барганда, сырхауханәдә чират күп иде. Балалар авыргач, бик яман. Сарымсак тагып, лимон, имбир суы эчеп кенә чирне җиңеп булмый, табиб кушканны үтәргә тырышабыз, – ди Гөлия Хәсәнова.

Азино балалар хастаханәсенең табиб-педиатры Анна Шишковадан ОРВИ белән авыручыларның ни сәбәпле артуы, аны кисәтү чаралары турында кызыксындык.

– Хәзер кыш бит. Быел ул башкачарак та әле. Җылыта да, дымлы һава да саклана. Шуңа күрә сулыш юлы авырулары артты. Балалар бакча һәм мәктәпләргә йөри, алар бер-берсе белән аралаша. Хәзер бәйрәм чаралары башлана. Кибетләргә дә азрак йөрергә тырышыгыз. Шуңа әти-әниләр балаларга карата игътибарлырак булсын иде. Әгәр йөткерсә, борыныннан акса, өйдә калдырыгыз. Хәлсезлек, температура югары булса, каты итеп йөткерә башласа, табибларга мөрәҗәгать итегез. Бакчадан кайткач, балаларның борын куышлыгын тозлы су катнашмасы белән юдыртырга кирәк. Кулларын, битләрен гел юып йөрсеннәр. Витаминнарны курслап эчертү дә җитми. Кыш көне С, Д витаминнары эчертегез. Салкын тидермәскә тырышыгыз, – диде Анна Шишкова.

Сәрия МИФТАХОВА

Эшсезләр кимегән

Октябрь аенда илдә эшсезлек дәрәҗәсе 4,3% тәшкил иткән. Соңгы елларда иң түбән күрсәткечләрнең берсе бу. Хезмәт һәм социаль яклау министры урынбасары Елена Мухтиярова шулай дип белдергән.

Хәзерге вакытта Россиядә 72,3 миллион кеше эш белән тәэмин ителгән. Мухтиярова әйтүенчә, Президент Владимир Путин билгеләгән мәшгульлек буенча күрсәткеч 400 мең кешегә арттырып үтәлгән. Росстат мәгълүматларына караганда, узган елда илдә эшсезләр саны 4,321 миллион чамасы булган. Бу 2019 елдагы күрсәткечтән 24,7 процентка зуррак, дип хәбәр итә ТАСС.

Кыш бабай иртәгә килә

Кыш бабай утырган поезд Казанга 15 декабрьдә килеп җитәчәк. Махсус поездда бөтен ил буйлап сәфәргә чыккан ул. Бәйрәмнең төп тылсымчысы өчен транспортны «Россия тимер юллары» әзерләгән. Кыш бабай сәяхәткә 5 декабрь көнне үзенең «туган җире» – Великий Устюгтан кузгалган. Сәфәре барышында Россиянең 36 шәһәрендә булачак. Кыш бабай Казанга 15 декабрь көнне иртән 9 тулып 25 минутта киләчәк, кичке 7дә китәчәк. Теләге булган бар кеше кышкы тылсымчыны каршы ала, озата, бәйрәмдә катнаша алачак. Билет алучыларны поездда Кыш бабай белән очрашу көтә.

Узган елгыдан күбрәк төзиләр

Республикада торак төзелеше мәйданы узган елның шушы ук чорындагы күрсәткечтән 4 процентка зуррак. Барлыгы 2 миллион 637 мең кв. метр торак мәйданы файдалануга тапшырылган. Быелгы план 99 процентка диярлек үтәлгән. Хөкүмәт Йортында узган киңәшмәдә төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллин шулай дип белдерде. Шәхси торак төзелеше буенча пландагы күрсәткеч 51 процентка арттырып үтәлгән: барлыгы 12581 йорт калкып чыккан (пландагы күрсәткеч – 8330). Коммерцияле төзелеш 63 процентка үтәлгән: күпфатирлы 102 торак йорт әзер, тагын 41ендә төзелеш эшләре тәмамланып килә. Социаль ипотека программасы буенча еллык төзелеш планы – 280 мең кв. м (161 йорт). Әлегә 147 мең кв.м торак мәйданы төзелгән. Бу пландагы күрсәткечнең 52 процентын тәшкил итә.

1100 еллыкны каршылап

Берләштерәчәк вакыйга

vk.com

1100 еллыкка 70тән артык чара. Россия вице-премьеры Марат Хөснуллин Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу уңаеннан бәйрәмгә әзерлек һәм аны уздыру буенча төп чаралар планын раслады. Вакыйгалар Татарстан гына түгел, башка төбәкләргә дә кагылачак.

– 71 чара үткәрү планы расланды. Җыен оештыру комитетының беренче утырышында без әзерлекнең төп юнәлешләрен билгеләдек, хәзер исә төгәл эшләр тәгаенләнде, – диде Хөкүмәт Рәисе урынбасары Марат Хөснуллин. – Ил Президенты да диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне саклау традициясенең мөһимлеген гел әйтеп тора. Бу – безнең байлыгыбыз.

Марат Хөснуллин әйтүенчә, республикада фәнни, мәдәни-агарту чаралары оештырылачак. Алар исә Идел буе Болгарында ислам динен кабул итүнең әһәмиятен, әлеге тарихи вакыйганың кешеләрне берләштерү өчен ни дәрәҗәдә мөһим булуын күрсәтергә тиеш.

Марат Хөснуллин сүзләренчә, 1100 еллыкны бәйрәм итү уңаеннан Казанда Җәмигъ мәчете комплексын төзү мәсьәләсе дә күтәрелә. План буенча, бу комплекс үз эченә музей, китапханә, күргәзмә-лекция залларын алачак.

Әһәмиятле чаралар исемлегендә Татарстан башкаласында төрле китапханә һәм фәнни оешмаларның фондларында ислам диненә кагылышлы кулъязма чыганакларны туплау, саклау һәм фәнни әйләнешкә кертү буенча үзәк төзү нияте дә бар.

Вице-премьер, үзгәрешләр башка төбәкләргә дә кагылачак, дип ышандырды. Аерым алганда, бу – Ульяновск өлкәсе, Түбән Новгород, Мәскәү һәм башка шәһәрләрдә оештырылачак чаралар.

Рөстәм МИҢНЕХАНОВ, Татарстан Президенты:
– Идел буе Болгары тарихы Россия тарихының һәм илебездә яшәүче халыкларның аерылгысыз өлеше булып тора. Тантаналы чарага әзерлек кысасында шактый эш башкарылды. Чаралар планы күп кенә көнүзәк мәсьәләләргә кагыла. Аларның кайберләре хәтта халыкара әһәмияткә ия. Шулар арасында Ислам хезмәттәшлеге оешмасы җитәкчелеге катнашында «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме утырышы, «Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit» халыкара икътисади саммиты. Казанда узачак ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы комитетының 45 нче сессиясе кысасында Россия мөселманнарының бай дини мирасын ачу, ислам дөньясында илнең йөзен һәм абруен күтәрү чаралары буларак хезмәт итәчәк алар. Болар барысы да дөнья җәмәгатьчелегенә Россия үсешенең үзенчәлеген, Көнчыгыш һәм Көнбатыш мәдәниятләренең тыгыз үрелеп баруын, динара бәйләнешне күрсәтергә мөмкинлек бирәчәк.

Сүзгә-сүз

Илсур МЕТШИН, Казан мэры:

Минем хыялым – бер генә чыршы да киселмәсен иде. Әмма бу – урманчылыкларның кереме, һәм безнең бурыч – чыршы базарларын оештыру. Чыршы белән сәүдә итүдә тәртип булырга тиеш.

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫНДА – КЕРЕМ

Татарстанның авыл хуҗалыгы оешмалары җитештерелгән продукция сатудан быелның 11 аенда 113 млрд сумлык керем алган. Шуның 78 млрд сумы терлекчелек тармагына туры килә. Бу – узган елның шул чоры белән чагыштырганда 16 процентка күбрәк.

ҖИТЕШТЕРЕЛГӘН ПРОДУКЦИЯ КҮЛӘМЕ

Сөт	1 млн 316 мең тонна – 30 млрд сум (109%)
Терлек һәм кош ите	377 мең тонна – 42 млрд сум (120%)
Йомырка	1 млрд данә – 5,4 млрд сум (136%)

Наркосәүдәгәрләр тотылган

Республикада наркотиклар сату буенча интернет-кибет оештыруда, шулай ук тыелган матдәләр таратуда шикле берьюлы 7 кешене тоткарлаганнар. Бу хакта Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы матбугат хезмәте хәбәр итә. Полиция хезмәткәрләре иң элек Түбән Камада яшәүче ике кешенең эзенә төшкән. Алар курьер ролен үтәгән – интернет-кибеттә заказлар алып, товар ташыган. Тоткарланган бер егетнең машинасында 190 грамм синтетик наркотик табылган. Фатирын тентү барышында полиция хезмәткәрләре 1,5 граммнан артыграк марихуанага тап булган. Икенчесеннән ярты граммнан аз гына күбрәк күләмдә наркотик тоз алынган. Моннан тыш, хокук сакчылары «Малиновка» постында «Мерседес» автомобилен туктатып, машина йөртүче 29 яшьлек егеттә 200 г мефедрон тапкан. Ул наркотиклар сату буенча интернет-кибет оештыручы булып торуын, шулай ук наркотикларны үзе җитештереп сатуын таныган. Бераз соңрак Түбән Камадагы бер йорт тирәсендә абыйлы-энеле ике туган тоткарланган. Боларының өендә 5 килодан артыграк наркотик табылган. Арендага алынган фатирда нарколаборатория оештырылуы, наркотикларның шунда киптерелүе һәм төргәкләнүе ачыкланган. Берникадәр вакыттан соң наркотикларны күпләп куеп китүче (закладчик) тоткарланган. Полиция хезмәткәрләре аның фатирында наркотиклы 60 төргәк тапкан. Ә инде иң ахырдан интернет-кибет операторы – 22 яшьлек кыз хокук сакчылары кармагына эләккән. «Барлыгы 20 килограммнан артыграк наркотик, лаборатория җиһазлары һәм химик матдәләр табылган», – дип хәбәр иткән Россия Эчке эшләр министрлыгының рәсми вәкиле Ирина Волк.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

РЕЙГАН ЧОРЫНА КАЙТКАНДА

Үткән атнада дөнья яңалыкларында ике төп тема алга чыкты: беренчесе «омикрон» штаммы булса, икенчесе долларга һәм фонд базарына бәйле икътисад проблемалары иде. «омикрон» зур тизлектә тарала һәм аннан котылып калып булырга охшамаган. Рәсми хәбәрләр аның белән авыручыларның күпчелеге тулысынча вакциналанган булуын һәм яңа штаммның элек авыручыларны да аямавын әйтәләр. Бу медальнең бер ягы гына, икенче ягы өметләндерә торган хәбәрләрдән тора. Әлегә кадәр «омикрон»нан үлүче бер генә кеше дә юк. Үткән тәүлекләрдә Израильдә ике бала яңа штаммнан үлде дигән рәсми хәбәрләр таралган иде. Ул хәбәрне Министрлар Кабинеты утырышында Премьер-министр Нафтали Беннет яңгыратты, әмма инде сүзләрен дөреслеккә туры килми дип кире алды һәм гафу үтенде. Чирләүчеләр арасында авыр хәлдәгеләр булу да ишетелми хәтта. Вакцинадан акча савып, зур байлыклар туплаган олигарх Билл Гейтс та, киләсе елда коронавирус пандемиясе туктар, дип сөендерә. Аның туктавында «омикрон» төп рольне үтәр, мөгаен. Күпчелек табиблар, яңа штамм тиз генә кешелек җәмгыятен әйләнеп чыгар да күмәк иммунитет бирер, дип өметләндерәләр. Каты авырып алучылар да булыр, мөгаен, әмма афәт үтәр дип көтик.

2022 елның төп проблемасы икътисад белән бәйле булыр кебек. Океан артыннан килгән рәсми хәбәрләр АКШта бәяләрнең рекордлы күтәрелүен бәян итәләр. Акча станогы долларларны залп белән атып торганда, башкача була да алмый инде ул. Үткән җомгада Америка Хезмәт министрлыгы инфляциянең еллык күләме 6,8 процентка җитүен белдерде. Мондый югары күрсәткеч үткән гасырда ил белән Рональд Рейган идарә иткәндә, 1982 елның мартында гына күзәтелгән икән. Дүрт-биш тапкыр кыйммәтләнгән товарлар да бар. АКШта базарлар бездәгегә караганда да ныграк селкенде үткән җәйдә.

Америка федераль резерв системасының (ФРС) «санлы йомшарту» дигән стимуллаштыру программасы бар. Инфляциянең алга ыргылуы бу программаның тукталуын һәм процент ставкалары күтәрелүне тизләтәчәк, ди белгечләр. Ноябрьдән башлап инде ФРС болай да активлар сатып алуны киметкән иде. Бу фонд базарында җиңелчә тетрәнү китереп чыгарды. Трансмилли бизнес ияләре үз компанияләренең акцияләрен күпләп сата башладылар. Бәя югары булганда сатып калмасаң, биржа түнтәрелеше башланып, куыклар шиңгәч, акчасыз каласың. Estee Lauder дип аталган косметика империясе хуҗасы миллиардер Рональд Лаудер һәм Google компаниясенә нигез салган Ларри Пейдж белән Сергей Бриннар тарихта беренче тапкыр үз компанияләренең акцияләрен күпләп саталар. Башка атаклы миллиардерларның да кыйммәтле кәгазьләрдән котылырга омтылуы күзәтелә. Белгечләр бу хәлне «тиңе булмаган картина» дип бәяләделәр. Әлегә масштаблы биржа түнтәрелеше күзәтелми күзәтелүен, әмма җимерелүнең гөрелтесе ишетелә инде.

Бу вазгыятьтә гади халык өчен куркыныч юк та кебек инде. Безнең бит кесәләрдә югалтасы миллиардлар күренми. Әмма хәл барыбер куркыныч. Бердән, базарлар җимерелсә, массакүләм эшсезлек башланачак. Бәяләр төшәргә мөмкин, әмма товар сатып алу өчен акча табылмас. Андый вазгыятьтә финанс мафиясе халыкларның игътибарын читкә юнәлтә торган икенче бер зур проблема тудырырга ярата. Менә шунысы белән хәтәр дә инде фонд базарында күпләп сату (распродажа) башлану.

Россиядә

ЯҢА КҮТӘРЕЛЕШНЕ КӨТКӘНДӘ

Инфляция Америкада гына биесә, без аңа артык пошынмас та идек, бәлки. Әмма Россия, глобаль капитализмның бер базары буларак, бәяләр узышында паровозның алдыннан чаба шул. Үтеп баручы ел безне котырган бәяләр белән аеруча нык сынады. Бер кесәгә, бер бәяләргә карыйсың да, инде бүтән бәя күтәрелергә җай калмады дип уйлыйсың. Әмма базарлар бу өлкәдә киң мөмкинлекләр барлыгына кат-кат ышандыра. Үткән җомгада федераль хөкүмәт вице-премьеры Андрей Белоусов әфәнде алдагы елда азык-төлек инфляциясенең өченче дулкыны көтелүен әйтеп «сөендерде». Бу хәбәр вице-премьер авызыннан «Россиядә эшләнгән» («Сделано в России») дигән форумда өзелеп төште. Хөкүмәт әһеле азык-төлеккә бәяләр күтәрелеше 2022 елның икенче яртысында башланыр дип вәгъдә итә.

Росстат кәрҗине азык-төлеккә еллык инфляция 10,6 процент тәшкил итүен күрсәтә. Бәяләр узышында тавык ите 30,27 процентлык күрсәткеч белән алда бара икән. Киләсе пандемия кош гриппына бәйле булачак, дип куркыткан вирусологлар бар. Шуңа күрә кыйммәт булса да, яратасыз икән, тавык ите ашап калыгыз. Пандемиясе, бәлки, булмас та, әмма шуның белән куркытып, кош фабрикаларын утильләштерсәләр, беркая да бара алмыйсың. Бу процесс бара бит инде. Ите күтәрелгәч, йомыркасы да тик тора алмый инде аның. Тавык йомыркасы быел 24,33 процентка кыйммәтләнде, ди статистика. Бу юлларны язучы автор йомырка сатып алмый, шуңа күрә белеп үк бетерми аның кибеттәге бәясен. Тик без тавыкка сибә торган бодай белән арпа бәясе үсеп тә күрсәтте соң бу көздә! Өч тапкыр диярлек кыйммәтләнделәр. Шулай булгач кибеттәгесе, мөгаен, арзанрактыр да әле аның. Әмма без күңел төшермибез.

Бәрәңге – 66,75 процентка, кәбестә бәясе 114,68 процентка күтәрелде дигән юллар да бик куркытмый безне. Беренчесен үзебез казып алдык, икенчесе көндәлек ризык түгел. Уртача азык-төлек инфляциясенең 10,6 процент белән генә бәяләнүе аптырата. Мин караган рәсми саннар арасында бер дә андый түбән күрсәткечкә ия булган товар күренми. Росстатта, мөгаен, махсус формула белән эшли торган калькулятор бардыр. Белоусов әфәнде менә бу күрсәткечләрне икенче дулкын саннары дип атый һәм киләсе елга өченче дулкынны вәгъдә итә.

Кәгазь валюталар бөтен дөньяда очсызлана. Бәяләр узышының төп сәбәбе шунда. «Долларлар юкка чыгачак, алардан котылыгыз!» – дип коткы таратучы икътисадчылар да күренә. Бердәнбер ышанычлы актив – алтын, дип әйтә белгечләр. Таможня федераль хезмәте гыйнвар – октябрь айларында Россиянең 240,5 тонна алтынны читкә экспортлавын әйтә. Бу илдә табылган бөтен алтын күләменә тиң дип әйтерлек күрсәткеч икән. Тавык ите белән кәбестә – бәя ягыннан шәп активлар инде алар, әмма аларны сандыкта саклап булмый. Бәс, шулай булгач, алтын сатып алыгыз. Ашаудан акчагыз артса инде.

tatarstan.ru

Рөстәм Миңнеханов башкаланың медицина учреждениеләренә беренче медицина-санитар ярдәм күрсәтү өчен автомобиль ачкычлары тапшырды. Президент транспорт алу өчен сертификатны Казан баш табибларының һөнәри берләшмәсе җитәкчесе Таиса Черновага тапшырды.

«Әлеге транспорт халыкка медицина хезмәте күрсәтүнең сыйфатын яхшыртырга, тизлекне арттырырга ярдәм итәчәк, күбрәк хәрәкәт итү мөмкинлеге бирәчәк, дип уйлыйбыз. Сәламәтлек саклауга һәрвакыт игътибар бирәбез», – диде Татарстан Президенты. Ул барлык медицина хезмәткәрләренә, шулай ук хезмәт коллективларына коронавируска каршы көрәштә инде ике ел дәвамында көн саен башкарган эшләре өчен рәхмәт белдерде. Рөстәм Миңнеханов сүзләренчә, барыннан да бигрәк Казан табибларына авырга туры килә.

37 Lada Largus автомобилен 23 сәламәтлек саклау учреждениесенә тапшырдылар. Президентның «Бәләкәч» программасы буенча ике «Газель Некст» машинасы Казанның 4 нче балалар сырхауханәсенә һәм 7 нче балалар шәһәр хастаханәсенә тапшырылды. Әлеге программаның максаты – өч яшькә кадәрге балаларны бушлай сөт ризыгы белән тәэмин итү.

РӘСМИ ХӘБӘРЛӘР

Хөкүмәт Йортында яшь галимнәргә ярдәм итү турында сөйләштеләр. Президент Рөстәм Миңнеханов Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты доценты, Татарстанның яшь галимнәр һәм белгечләр хәрәкәте башкарма комитеты рәисе Юлия Кариева белән очрашты.

Узган атнада Яшь галимнәр конгрессында Россия Президенты Владимир Путин белән очрашуда Юлия Кариева социаль ипотека һәм торак сертификатлары алганда галимнәрнең казанышларын да исәпкә алырга тәкъдим итте. Әлегә мондый ярдәм чараларыннан мохтаҗ дип саналган белгечләр генә файдалана ала. Моннан тыш, ул әлеге программаларны Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагында булмаган оешмаларга да кертергә тәкъдим итте.

Очрашу барышында Рөстәм Миңнеханов һәм Юлия Кариева яшь галимнәргә ярдәм итү турында җентекләп фикер алыштылар. «Бу – бик мөһим һәм көн кадагындагы мәсьәлә. Татарстанда моңа зур игътибар бирелә», – диде Президент. Очрашу нәтиҗәләре буенча Рөстәм Миңнеханов Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык, Яшьләр эшләре министрлыгына да тәкъдимнәр әзерләргә кушты.

* * *

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Россия Закон чыгаручылар советы президиумы утырышында катнашты. Видеоэлемтә рәвешендә узган җыелышта депутатлар, төбәкләрнең башкарма хакимият органнары, законнар чыгару җыеннары вәкилләре социаль әһәмиятле мәсьәләләр буенча фикер алышты.

Аерым алганда, социаль һәм медицина хезмәтләре күрсәтү, шулай ук коронавирус инфекциясе таралу шартларында ерактагы, юлсыз районнарга йөкләр ташуны оештыру турында сүз барды. Утырышта Дума Рәисе урынбасары Ирина Яровая кайбер тәкъдимнәр белән чыкты. Ул, аерым алганда, медицина оешмалары арасында сырхау турында мәгълүматлар алышу һәм диспансеризация нәтиҗәләре буенча бушлай белешмәләр алу мөмкинлеген күздә тотуны тәкъдим итте.

СИҢА ДА, МИҢА ДА

ЯҢА ЕЛДАН QR-КОДНЫ АНТИТӘНЧЕКЛӘРГӘ КАРАП БИРӘЧӘКЛӘР

Яңа атна коронавирус инфекциясенә бәйле яңалыклар алып килде. Алар антитәнчекләре булганнарга QR-код бирү, «омикрон» штаммы һәм гомуми вазгыятькә бәйле.

Хөкүмәт Йортында узган «шимбә киңәшмәсе» вакытында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов республиканың коронавируслы вазгыятьнең кайсы борылышына да әзер булырга тиешлеген искәртте. «Омикрон» штаммы йогынтысында вазгыять катлауланган очракта, сырхаулар өчен обсерваторлар булдырырга һәм аларны тиз арада җәелдерергә кирәк булачак. Президент әйтүенчә, вирус дөньяның 50ләп илендә ачыкланган. Россия дә искәрмә түгел. Инфекцияне Төркия, Мисыр, Берләшкән Гарәп Әмирлекләреннән йоктырып кайту ихтималы да зур һәм бу аеруча борчу тудыра. Ял итәргә күпчелек шунда бара бит. Президент әйтүенчә, Роспотребнадзор идарәсе штаммның үтеп керүенә юл куймас өчен барысын да эшли.

– Безнең система моңа әзер булырга тиеш. Җебеп торырга вакыт юк, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Вазгыятьне контрольдә тоту өчен кирәкле бар нәрсә оештырылган. Кирәк икән, без обсерваторларны ачарга әзер торырга тиеш.

Татарстанда халыкка вакцина ясау эше дә дәвам итә. Президент әлегә бу оешкан төстә һәм яхшы темплар бара дигән фикердә. «Минемчә, бу – Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм районнарыбызның системалы эше нәтиҗәсе. Хәрәкәт бар», – диде ул.

Дмитрий ПЕСКОВ,
Россия Президентының матбугат сәркатибе:

> Җәмәгать транспортында QR-код кертү турында закон проекты җитди эшкәртүне таләп итә. Аның бик катлаулы закон проекты булуы ачыкланды. Әлегә аның тискәре нәтиҗәләргә китермәячәгенә ышандырып булмый. Шуңа күрә аны Дәүләт Думасында караудан алырга карар кылдылар. Моңа карамастан, аны камилләштерү юнәлешендә эш дәвам итәчәк. Россия Президенты башта ук, мондый катлаулы закон проектларын караганда кешеләрнең мәнфәгатьләре өстенлек итәргә тиеш, дип әйткән иде.

Билгеле булганча, Татарстан буенча барлыгы 175 прививка кадату пункты эшли. Шуларның икесе тәүлек әйләнәсе хезмәт күрсәтә. Хәзерге вакытта 2223761 вакцина ясаткан, 1856987се прививканың икенче дозасын алган.

QR-код системасына бәйле үзгәрешләр дә көтелә. Россия вице-премьеры Татьяна Голикова шулар турында Дәүләт Думасы утырышында хәбәр итте. Үзгәрешләр 2022 елның 1 гыйнварыннан көтелә.

Россиядә коронавирус белән авыру турында белешмәне (QR-код) чирләгән, әмма медицина ярдәме сорап мөрәҗәгать итмәгән кешеләр дә алачак. Аларга антитәнчекләр булуын раслаучы анализ тапшырырга кирәк булачак.

Белешмәне 2021 елның 1 гыйнварыннан соң коронавирус кичергән кешеләр алачак. QR-кодлы булуга антитәнчекләрнең нинди күләмдә булуы тәэсир итми.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Антитәнчекләр турында мәгълүмат коронавируска каршы уңай тестлар базасы белән чагыштырылачак. Әгәр кеше коронавируска ПЦР-тест тапшырган һәм соңыннан аның тәнендә антитәнчекләр булуы расланган икән, аңа бер ел гамәлдә булачак белешмә бирелә. Тест бирмәгән, әмма антитәнчекләре бар икән, QR-код ярты ел гамәлдә булачак.

Моңа өстәп, коронавируска каршы чит ил вакцинасын ясаткан кешеләргә дә, антитәнчекләргә тест тапшырып, QR-кодлы булу мөмкинлеге бирелә. Ул да ярты ел гамәлдә булачак. «Спутник V» вакцинасын башка илләрдә ясаткан Россия халкы да, антитәнчеккә анализ тапшырып, белешмәле булачак.

Вице-премьер искәрткәнчә, «медотвод»ы булган кешеләр дә, ПЦР-тестның тискәре нәтиҗәсе булган очракта, җәмәгать урыннарына кертеләчәк.

БАЛЫКЧЫЛАР:

«Боз үзенә тарта»

tatarstan.ru

Яшәеш

Татарстанның кайбер елгаларын әле боз капламаган. Шуңа да белгечләр юка бозга кермәскә куша. Сулыкларга бозның калынлыгы 7 сантиметр булса гына керергә ярый. Бу таләпне үтәмәүчеләрне штраф көтә. Тик балык җене кагылган кешеләрне штраф белән генә куркытып булмый.

– Боз үзенә тарта инде ул, – ди 42 ел буе Чулманга кармак салучы Илдар абый Шәрипов. – Өйдәгеләр мырлап торса да, күңел үзенчә эшли. Аңа әмер биреп булмый. Мин үзем – өч тапкыр үлемнән калган кеше. Өчесендә дә боз астына киттем. Аллага шөкер, гомер бетмәгәч, яшисең икән. Икесендә дуслар коткарды, өченчесендә үзем бозга ябышып чыга алдым. Боларны хатынга сөйләп тору юк инде. «Ташлыйм кармакны», – дигән чакларым да булды. Әмма ике-өч көннән тагын киенеп чыгып китәм.

Ә менә Түбән Камада гомер итүче Назыйм Галиәхмәтовның хатыны иренең балык тотуын хупламый гына.

– Өйләнешкәнебезгә – 35 ел. Назыйм абыең аңа кадәр дә балык тоткан. Өйләнгәч тә туктамады. Кармак салуның никадәр рәхәт икәнен белә ул. Мин аның кичтән балыкка әзерләнүен карап торып та шаккатам. Ипләп кенә бөтен кирәк-ярагын хәстәрли. Башка вакыттагы кебек берни сорап аптыратмый. Һәр нәрсәсен үзе табып ала, – ди хатыны Әлфия апа. – Мин аның бу шөгылен аңлыйм. Шуңа да каршы килеп, эч пошырып тормыйм. Ул бит балыкка ялгызы гына йөрми. Һәрчак янында туганнары була. Шуңа җаным тыныч.

Узган елларда Кама Тамагы районы янәшәсендә Идел елгасында өч балыкчы ярга чыга алмыйча кала. Алда әйтелгәнчә, елгаларның ачык калган өлешләре бар әле. Ирләрнең берсе ярга сикереп кенә чыкмакчы була, әмма суга төшә. Янындагы ике дусты аны тартып ала. Кызганыч, аларга ярга чыгу өчен коткаручылар ярдәме кирәк була. Бозга техника белән кергән ир-ат та судан үзе генә чыга алмый. Аны да коткаралар.

– Күп кенә елгаларда боз ышанычлы түгел. Әлегә сулыкларга техника белән керү бөтенләй тыела. Шуңа күрә, керми торсалар иде, – ди Татарстан Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының матбугат үзәге җитәкчесе Андрей Родыгин.

Сулыклардагы күңелсез хәлләрне булдырмас өчен, Татарстанның гадәттән тыш хәлләр министры Рафис Хәбибуллин кушуы буенча 22 ноябрьдән вакытлыча коткару пунктлары тәүлек буе эшли башлады. Алар балыкчылар еш йөргән урыннарда урнашкан. Коткаручылар фикеренчә, мондый постлар күңелсез хәлләрне кисәтергә ярдәм итәчәк. Әлеге урыннар Казан, Чаллы, Чистай, Яшел Үзән, Алексеевск, Кама Тамагы, Лаеш, Минзәлә, Түбән Кама районнарында урнашкан. Елгалар бозланганнан бирле республикада 8 кешене коткарганнар.

Бозга ничек керәсе?

✓ Бозга кергәндә, үзең белән таяк алырга кирәк. Аның белән суккалап алгач, шул урында су чыкса, аннан тизрәк китегез.

✓ Бер боз кисәгендә берничә кеше җыелып торырга тиеш түгел. Берничә кеше булганда, алар бер-берсеннән биш-алты метр ераклыкта барырга тиеш.

✓ Бозда сикерергә яки йөгерергә ярамый. Караңгы вакытта бозга бөтенләй кермәгез.

✓ Төннән соң боз каты һәм ышанычлы тоела, әмма иртән аңа алданып керергә ярамый. Көндез ул бик тиз эри. Юка бозга кергән очракта, аннан кире чыкканда, аягыгызны шудырып, боздан алмыйча гына чыгыгыз.

Юка бозга кергән өчен 1500дән 2000 сумга кадәр штраф каралган.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Кулда сакламау хәерле

Акча алышына икән! Елның-елында декабрь аенда халык арасында шундый сүз тарала. Бу көннәрдә дә күпләр әнә шул хакта баш катыра. Яңа елдан нәрсә көтәргә?

Халык арасында уздырылган соңгы сораштыру нәтиҗәләреннән күренгәнчә, бүген ил халкының өчтән бере (34 процент) Яңа елдан соң акча алышыначак, дип курка. Бу төркемгә кергән респондентларның күпчелеге бәйрәмнән соң сум очсызланачак, доллар 81–82 сумга, евро 92 сумга җитәргә мөмкин дип фаразлый. Икътисад тармагында кайнаган белгечләрнең дә күбесе бу фараз белән килешә. «Альфа-банк»ның баш икътисадчысы Наталья Орлова сүзләренә караганда, яңа ел башыннан сум берничә фактор аркасында кыйммәтен югалтырга мөмкин. «Омикрон» штаммы барлыкка килү сәбәпле, пандемиянең яңа дулкыны башлану, нефть котировкалары төшү, Россиянең финанс тармагына карата яңа чикләүләр кертү аркасында, Яңа елдан соң сум бик нык очсызланырга мөмкин. Шулай да доллар 100 сумга кадәр үк җитмәс дип уйлыйм», – дип фаразлый белгеч.

Казан дәүләт аграр университеты доценты, икътисадчы Илгизәр Гайнетдинов, әлегә икътисадта акча алышынырга сәбәпләр юк, дигән фикердә.

– Акча, инфляция бик нык үсеп, безнең акча бик нык арзанайса, аның массасын йөртергә уңайсыз була башласа, алышына. Якын арада инфляция үсеше якынча 7,5–8 процент чамасында булыр дип көтелә. Бу куркыныч сан түгел. Аннары пандемия вакытында икътисадта да әллә ни үсеш юк әле. Мондый шартларда халкы турында уйлаган хөкүмәт мондый адымга бармас дип уйлыйм, – ди белгеч.

Илгизәр Гайнетдинов акча алышыну турында имеш-мимешләр таралуның башка сәбәбен дә атый. Шул рәвешле халыкны куркыту банклар тарафыннан махсус уйлап табылган хәйләкәр алым да булырга мөмкин дип саный ул.

– Акча алышына икән, дигән сүзләр йөри башлауга, халык: «Кулдагы акчаны нәрсә эшләтергә икән?» – дип баш вата башлый бит. Акча алышынса, юкка чыгар дип курка. Бу банкларга бик кулай. Кешенең өйдә саклаган акчасын үзләренә китерүен телиләр, – ди ул. – Кулында азмы-күпме җыелган акчасы булган кеше аны фатир, кыйммәтле кирәк-ярак, көнкүреш техникасы алуга тота ала. 7–8 процентлы файдалы кертем вәгъдә итә торган ышанычлы банк табып, артык акчаны шунда сакласаң да хәерле. Билгеле булганча, физик затларның 1,4 миллион сумга кадәрге кертемнәре иминиятләштерелә, ягъни ул-бу була калса, бу акча кертемчегә кире кайтарылачак.

Сүз уңаеннан, белгечләр киләсе елның көзенә илдәге банкларның 8 проценты ябылырга мөмкин, дип фаразлый. «Эксперт РА» рейтинг агентлыгы уздырган тикшеренү нәтиҗәләреннән аңлашылганча, узган ел Россиядә барлыгы 45 банк ябылган.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2021 елның 25 ноябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законына (2020 елның 19 ноябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 12; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 87 (I өлеш)) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендәге 5 пунктының «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) оешманың еллык кеременнән кимендә 90 процентын аның булдырылган (төзелгән) йә реконструкцияләнгән һәм (яисә) модернизацияләнгән күчемсез мөлкәт объектларыннан һәм (яисә) үзара бәйле булган күчемле мөлкәт һәм күчемсез мөлкәт объектлары комплексыннан файдалану стадиясендә инвестиция проектын гамәлгә ашырудан һәм (яисә) интеллектуаль эшчәнлекнең булдырылган нәтиҗәләреннән һәм (яисә) аларга тиңләштерелгән индивидуальләштерү чараларын файдаланудан алынган кереме тәшкил итә;»;

2) 3 статьяда:

а) 1 өлештә:

түбәндәге эчтәлекле 2[1] пункт өстәргә:

«2[1]) «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 16 статьясындагы 22 өлешендә күрсәтелгән очракларда, капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру хакында килешү төзү турындагы гаризаны, аңа кушып бирелә торган документларны һәм материалларны капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру хакындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешма билгеләренә туры килүче Россия юридик затына кире кайтару тәртибен раслау;»;

3 пункты түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү шартларын һәм үзенә карата мондый килешү төзелгән инвестиция проектын гамәлгә ашыру, шул исәптән аны башкару этапларын гамәлгә ашыру, шартларын үтәүне мониторинглауны башкару тәртибен раслау;»;

5 пункты түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган гомуми таләпләр нигезендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешма тарафыннан тотылган, әлеге Законның 9 статьясындагы 1 өлешендә каралган чыгымнарны каплау тәртибен раслау;»;

б) 2 өлешнең 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

3) 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9 статья. **Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектларына дәүләт ярдәме чаралары**

1. Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешмага Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә чыгымнарны каплауны һәм (яисә) салымнар һәм җыемнар хакындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнгән салымны кайтаруны күздә тоткан дәүләт ярдәме чарасы түбәндәге чыгымнарга бирелергә мөмкин:

1) инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган тәэмин итүче һәм (яисә) тиешле инфраструктуралар объектларын булдыруга (төзүгә) йә реконструкцияләүгә һәм (яисә) модернизацияләүгә, шул исәптән дәүләт (муниципаль) милкендәге яисә җайга салына торган оешмалар милкендәге инфраструктура объектларын реконструкцияләүгә (инженерлык һәм транспорт челтәрләренә технологик тоташтыру (тоташу) чыгымнарын да кертеп);

2) инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган тәэмин итүче һәм (яисә) тиешле инфраструктуралар объектларын булдыру (төзү) йә реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү өчен җәлеп ителгән кредитлар һәм заемнар буенча процентларны, облигация заемнары буенча купон керемен түләүгә, шул исәптән дәүләт (муниципаль) милкендәге инфраструктура объектларын реконструкцияләүгә;

3) инвестиция проектын яңа күчемсез мөлкәт объектларын һәм (яисә) үзара бәйле булган күчемле мөлкәт һәм күчемсез мөлкәт объектлары комплексын булдыру (төзү) йә гамәлдәгеләрен реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү, һәм (яисә) интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләрен һәм (яисә) аларга тиңләштерелгән индивидуальләштерү чараларын булдыру өлешендә гамәлгә ашыру өчен җәлеп ителгән кредитлар һәм заемнар буенча процентларны, облигация заемнары буенча купон керемен түләүгә, мондый процентлар инвестиция стадиясендә түләнгән булса һәм мондый кредитларга һәм заемнарга, облигация заемнарын да кертеп, дәүләт ярдәменең башка чаралары бирелмәгән булса;

4) аларны үткәрү нәтиҗәсендә яңа технология барлыкка килгән фәнни тикшеренүләргә һәм (яисә) тәҗрибә-конструкторлык эшләнмәләренә, түбәндәге шартлар бер үк вакытта үтәлгән очракта:

а) интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәсе буларак эшләнгән яңа технология дәүләт теркәвенә алынган булса, мондый технология хокукына капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешма ия булса;

б) капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешма тарафыннан инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында эшләнгән яңа технология нигезендә сәнәгать продукциясен серияле җитештерү гамәлгә ашырылса;

в) чыгымнарның каплана торган төрләре исемлеге Россия Федерациясе Салым кодексының 262 статьясындагы 2 пунктының 2, 3, 4 һәм 5 пунктчаларында каралган фәнни тикшеренүләргә һәм (яисә) тәҗрибә-конструкторлык эшләнмәләренә чыгымнар нигезендә билгеләнсә;

г) капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешманың «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 15 статьясындагы 6 һәм 7 өлешләрендә каралган чыгымнары каплау срогы дәвамында инвестиция проекты буенча еллык гомуми кереме кимендә 80 процентын эшләнгән яңа технология нигезендә җитештерелгән сәнәгать продукциясен сатудан алган табыш тәшкил итсә;

5) хәрби шәһәрчекләр территорияләрендәге объектларны сүтүгә (торак төзелеше өлешендә), түбәндәге шартлар бер үк вакытта үтәлгәндә:

а) вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан аның карамагындагы күрсәтелгән объектларны яңадан урнаштыру турында карар кабул ителсә;

б) капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешма акчалары исәбеннән әлеге объектларны яңадан урнаштыру чаралары гамәлгә ашырылса, шул исәптән, кирәк булганда, мондый объектларны сүтү эшләре башкарылса;

в) хәрби шәһәрчекләр территорияләрендәге яңа объектлар Россия Федерациясе милкенә рәсмиләштерелгән булса;

г) инвестиция проекты буенча капитал салулар күләме кимендә 10 миллиард сум тәшкил итсә.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән дәүләт ярдәме чарасы Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә субсидия рәвешендә һәм (яисә) салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнарында каралган башка рәвештә бирелә. Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру хакындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешма мондый дәүләт ярдәме чарасын бирү рәвешен сайлый һәм сайланган рәвешне әлеге статьяның 5 өлешендәге 5 пунктында каралган чыгымнарны каплау күләмен исәпләүдә күрсәтә.

3. Инвестиция проекты аның төп объекты буларак транспорт, энергетика инфраструктурасы объектын, коммуналь, социаль яисә цифрлы инфраструктура объектын булдыруны (төзүне) йә реконструкцияләүне һәм (яисә) модернизацияләүне күздә тотса (инвестиция проектының төп объекты дигәндә, транспорт, энергетика инфраструктурасы объекты, коммуналь, социаль яисә цифрлы инфраструктура объекты аңлашыла, аннан физик яисә юридик затларга объектның инфраструктурасыннан (товарларыннан, хезмәт күрсәтүләреннән) түләүле файдалана алу мөмкинлеген бирү рәвешендә файдаланудан еллык керем капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешманың «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 15 статьясындагы 6 һәм 7 өлешләре нигезендә билгеләнә торган чыгымнарны каплау срогы дәвамында инвестиция проектын гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә алган гомуми кеременнән кимендә 80 процентын тәшкил итә), түбәндәге чыгымнар каплана:

1) әлеге статьяның 1 өлешендәге 3–5 пунктларында каралган чыгымнар;

2) инвестиция проектының төп объектына керми торган һәм әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында каралган чыгымнарны каплау максатларында тәэмин итүче һәм (яисә) тиешле инфраструктуралар объектлары булып санала торган инфраструктура объектларына карата әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында каралган чыгымнар.

4. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән каплана торган чыгымнарның иң чик күләме һәм шушы чыгымнар каплануның иң чик срогы «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 15 статьясындагы 4–7 өлешләрендә каралган күләмнәрдән һәм сроклардан артык була алмый.

5. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән чыгымнарны каплау түбәндәге шартлар бер үк вакытта үтәлгәндә гамәлгә ашырыла:

1) инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында барлыкка килгән һәм дәүләт теркәвенә алынырга тиешле барлык мөлкәти хокуклар Россия Федерациясе законнары нигезендә теркәлгән, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләре һәм (яисә) аларга тиңләштерелгән индивидуальләштерү чаралары (кулланып булган очракта) дәүләт теркәвенә алынган, шулай ук, әгәр инвестиция проекты күчемсез мөлкәт объектларын булдыруны (төзүне) йә реконструкцияләүне күздә тоткан очракта, аларның бөтенесе дә булдырылган (төзелгән) йә реконструкцияләнгән һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә файдалануга тапшырылган булса;

2) капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешманың, инвестиция проектын гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешүнең бер ягы булган Татарстан Республикасы бюджетына түләү өчен мондый оешма тарафыннан исәпләнгән мәҗбүри түләүләрне, аерым алганда, оешмалар табышына салымны, оешмалар мөлкәтенә салымны, транспорт салымын түләү буенча бурычы булмаса;

3) «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешенең 7 пункты нигезендә раслана торган чыгымнарны каплау тәртибе белән каралган әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән чыгымнарны каплау нормативлары үтәлгән булса;

4) фәнни тикшеренүләр һәм (яисә) тәҗрибә-конструкторлык эшләнмәләре үткәрү нәтиҗәсендә яңа технология булдырылган һәм эшләнгән яңа технология нигезендә сәнәгать продукциясен серияле җитештерү гамәлгә ашырылса, мондый технология интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәсе буларак дәүләт теркәвенә алынган, шулай ук әлеге статьяның 1 өлешендәге 4 пунктында каралган башка шартлар үтәлгән булса (кулланып булган очракта);

5) капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешма, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән чыгымнарны каплау күләмен исәпләү нигезендә, ул шул исәптән «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 15 статьясындагы 9 өлешенең 5 пунктында күрсәтелгән шартларны да күздә тота, шушы чыгымнарны каплау күләмен исәпләүне биргән булса;

6) инвестиция проекты кысаларында булдырылырга (төзелергә) йә реконструкцияләнергә тиешле күчемсез мөлкәт (капиталь төзелеш) объектларының һәм линия объектларының проектлау документларына һәм аларның смета бәясен билгеләүнең дөреслеген тикшерүгә дәүләт экспертизасы уздыру турында уңай бәяләмә бирелгән булса;

7) технологик аудит һәм бәя аудиты үткәрү турындагы бәяләмәгә һәм эксперт оешмасына карата Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән таләпләр нигезендә эксперт оешмасы тарафыннан бирелгән, шул исәптән капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешма әзерләгән чыгымнарны каплау күләмен исәпләүне дә күздә тоткан мондый бәяләмә бирелгән булса;

8) капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешма тарафыннан әлеге статьяның 1 өлешендәге 5 пунктында каралган шартларны үтәүне раслаучы документлар бирелгән булса (кулланып булган очракта);

9) инвестиция проектына карата турыдан-туры дәүләт финанс ярдәменең башка чаралары бирелгән очракта, әлеге статьяның 1 өлешендә каралган чыгымнарны каплау, турыдан-туры дәүләт финанс ярдәменең бирелгән башка чараларын исәпкә кертмичә, «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә билгеләнгән мондый чыгымнарның иң чик күләменнән артмаган күләмдә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

6. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән чыгымнарны каплау капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешүдә каралган инвестиция проектын гамәлгә ашыруның аерым этаплары тәмамланганнан соң гамәлгә ашырылырга мөмкин. Инвестиция проектын гамәлгә ашыруның аерым этабы, әгәр мондый килешү инвестиция проектын башкаруның берничә этабын күздә тотса һәм түбәндәгеләр башкарылган булса, тәгәлләнгән дип санала:

1) аерым этап буенча күчемсез мөлкәт объектын (объектларын) булдыру (төзү) йә реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү тәмамланган, мондый объектлар Россия Федерациясе законнары нигезендә файдалануга тапшырылган һәм әлеге объектларга карата капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешманың милек хокукы теркәлгән йә мондый объект (объектлар) дәүләт (муниципаль) милкенә яисә җайга салына торган оешма милкенә тапшырылган булса;

2) күчемсез мөлкәт объектын (объектларын) булдырудан (төзүдән) йә реконструкцияләүдән һәм (яисә) модернизацияләүдән соң мондый объект (объектлар), булдырылуы (төзелүе), йә реконструкцияләве һәм (яисә) модернизацияләве капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешүдә каралган башка күчемсез мөлкәт объектларыннан бәйсез рәвештә, әлеге килешүдә каралган товарлар җитештерү, эшләр башкару яисә хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланылырга мөмкин.

7. Әлеге статьяның 6 өлеше нигезендә инвестиция проектын гамәлгә ашыруның аерым этабы тәмамланганнан соң әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән чыгымнарны каплау, әлеге статьяның 5 өлешендәге 2, 3, 5–8 пунктларында каралган шартлар үтәлгән очракта, аерым этапта төзелгән, реконструкцияләнгән һәм (яисә) модернизацияләнгән күчемсез мөлкәт объектыннан файдалану өчен кирәкле булган тәэмин итүче һәм (яисә) тиешле инфраструктуралар объектларына карата гамәлгә ашырыла. «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 15 статьясындагы 6 һәм 7 өлешләрендә күрсәтелгән сроклар әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән чыгымнарны каплауны башлау көненнән алып аерым этапта төзелгән, реконструкцияләнгән һәм (яисә) модернизацияләнгән күчемсез мөлкәт объектыннан (объектларыннан) файдалану өчен кирәкле булган тәэмин итүче һәм (яисә) тиешле инфраструктураларның барлык объектларына карата исәпләнә.

8. Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешма инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында барлыкка килгән һәм дәүләт теркәвенә алынырга тиешле барлык мөлкәти хокуклар Россия Федерациясе законнары нигезендә теркәлгән, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләре һәм (яисә) аларга тиңләштерелгән индивидуальләштерү чаралары (кулланып булган очракта) дәүләт теркәвенә алынган, шулай ук, әгәр инвестиция проекты күчемсез мөлкәт объектларын булдыруны (төзүне) йә реконструкцияләүне һәм (яисә) модернизацияләүне күздә тоткан очракта, аларның бөтенесе дә булдырылган (төзелгән) йә реконструкцияләнгән һәм (яисә) модернизацияләнгән һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә файдалануга тапшырылган көннән алып өч елдан да артмаган срокка әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән чыгымнарны каплау хокукыннан файдалана ала. Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешма, әлеге статьяның 6 һәм 7 өлешләрендә каралган шартлар үтәлгән очракта, инвестиция проектын гамәлгә ашыруның аерым этаплары тәмамланганнан соң тиешле этапта булдырылган (төзелгән) йә реконструкцияләнгән һәм (яисә) модернизацияләнгән күчемсез мөлкәт объектларына хокуклар дәүләт теркәвенә алынган көннән алып өч елдан да артмаган срокка әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән чыгымнарны каплау хокукыннан файдалана ала.

9. Инвестиция проектын гамәлгә ашыручы һәм хосусый проект инициативасы тәртибендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешү төзегән оешмалар инфраструктура объектларына чыгымнарны бүлү хакында үзара килешү төзи алалар. Инвестиция проектын гамәлгә ашыручы оешмалар үзара шундый килешү төзегән очракта, алар мондый шартнамәнең күчермәсен «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 7 статьясында каралган капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру хакында килешү төзү турындагы гаризага кушып бирәләр яисә инде төзелгән капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру хакындагы килешүне үзгәртү өчен мондый шартнамәнең күчермәсен «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 11 статьясында каралган тәртиптә җибәрәләр. Инвестиция проектын гамәлгә ашыручы оешмалар, әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән чыгымнарны каплау датасыннан да соңга калмыйча, инде төзелгән капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешүне үзгәртү өчен инфраструктура объектларына чыгымнарны бүлү хакындагы шартнамәнең күчермәсен җибәрә алалар. Әлеге өлештә каралган шартнамәдә инвестиция проектын гамәлгә ашыручы оешмаларның һәрберсенең тәэмин итүче һәм (яисә) тиешле инфраструктура объектларын булдыру (төзү) йә реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү чыгымнары турында мәгълүмат булырга тиеш. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән чыгымнар инвестиция проектын гамәлгә ашыручы һәм инфраструктура объектларына чыгымнарны бүлү хакында шартнамә төзегән һәр оешмага аның тарафыннан тотылган һәм аларны тоту факты Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә расланган чыгымнар күләмендә аерым каплана.

10. Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешма чыгымнарны каплау максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына әлеге статьяның 5 өлешендәге 5 – 7 пунктларында каралган чыгымнарны каплау күләмен исәпләүне, күчемсез мөлкәт (капиталь төзелеш) объектларының һәм линия объектларының проектлау документларына һәм аларның смета бәясен билгеләүнең дөреслеген тикшерүгә дәүләт экспертизасы уздыру хакындагы уңай бәяләмәне, технологик аудитның һәм бәя аудитының уңай бәяләмәсен, шулай ук исемлеге һәм составы «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешенең 7 пункты нигезендә раслана торган чыгымнарны каплау тәртибе белән билгеләнә торган башка документларны җибәрә.

11. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы әлеге статьяның 10 өлешендә каралган документларны, «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешенең 7 пункты нигезендә раслана торган чыгымнарны каплау тәртибенә таянып, аларның комплектлылыгы предметына тикшерә.

12. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән тиешле инфраструктура объектларына чыгымнарны каплау тиешле инфраструктура объектлары «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 13 пунктында каралган критерийларга туры килгән очракта гамәлгә ашырыла.

13. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән чыгымнарны каплау турында карар кабул ителгәндә, инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында булдырыла торган тиешле инфраструктураның дәүләт (муниципаль) милкенә тапшырыла торган яисә җайга салына торган оешманың милкенә керә торган объектларына хезмәт күрсәтүгә, аларны карап тотуга, алардан файдалануга (аларны бетерү мөмкинлеге белән) Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек) чыгымнарын финанс белән тәэмин итү чыганаклары билгеләнергә тиеш. Тиешле инфраструктура объектларын булдыру (төзү) йә реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү максатларында тотылган чыгымнарны каплаганда, милкенә тиешле инфраструктура объекты керә торган зат билгеләнергә тиеш. Күрсәтелгән объектны дәүләт (муниципаль) милкенә яисә җайга салына торган оешманың милкенә тапшыру өчен Татарстан Республикасының (муниципаль берәмлекнең) яисә җайга салына торган оешманың ризалыгы таләп ителә. Мондый ризалык әлеге статьяның 14 өлешендә каралган шартнамәдә (килешүдә) белдерелергә мөмкин.

14. Үзләренә карата чыгымнар «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль закон һәм әлеге Закон нигезендә капланырга тиешле булган тиешле инфраструктура объектларыннан файдалану һәм (яисә) аларны дәүләт (муниципаль) милкенә яисә җайга салына торган оешманың милкенә тапшыру үзенчәлекләре капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру хакындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешма һәм булдырылган тиешле инфраструктура объекты аннан алга таба файдалану өчен үз милкенә тапшырыла торган Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек) яисә үз милкенә керә торган җайга салынучы оешма арасындагы шартнамә (килешү) белән билгеләнә. Тиешле инфраструктура объектларын дәүләт (муниципаль) милкенә тапшыру яклар тарафыннан имзалана торган кабул итү-тапшыру акты нигезендә гамәлгә ашырыла.

15. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән дәүләт ярдәме чарасын финанс белән тәэмин ителеше капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешма акчалары исәбеннән тулысынча яисә өлешчә гамәлгә ашырыла торган җайга салынучы оешманың инвестиция программаларына кертелгән инфраструктура объектларына карата күрсәтү рөхсәт ителә. Бу очракта әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән каплана торган чыгымнар күләме капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешманың тәэмин итүче инфраструктура объектлары өчен инвестиция программасын финанс белән тәэмин итүгә фактта тотылган чыгымнарының 50 процентыннан һәм капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру хакындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешманың тиешле инфраструктура объектлары өчен инвестиция программасын финанс белән тәэмин итүгә фактта тотылган чыгымнарының 100 процентыннан артык була алмый.

16. Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешмага әлеге статьяда каралмаган ярдәм чаралары (шул исәптән дәүләт ярдәме чаралары) бирелергә мөмкин. Дәүләт ярдәме чаралары күләме, әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән дәүләт ярдәме чарасы күләменнән тыш, үзенә карата капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешү төзелгән яңа инвестиция проектын гамәлгә ашыруга юнәлдерелә торган капитал салулар күләменнән артмаска тиеш.»;

4) 13 статьяда:

а) беренче абзацта «Салым ташламалары» сүзләрен «1. Салым ташламалары» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

«2. «Электр энергиясен һәм егәрлеген күпләп сату базары кагыйдәләрен раслау турында һәм электр энергиясен һәм егәрлеген күпләп сату базарының эшләвен оештыру мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 27 декабрендәге 1172 номерлы карары нигезендә үткәрелгән конкурс нәтиҗәләре буенча сайлап алынган җитештерү һәм куллану калдыкларыннан файдалану нигезендә эшли торган генерация объектларын төзү (реконструкцияләү, модернизацияләү) буенча инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы инвестиция эшчәнлеге субъектларына салым ташламалары объектны файдалануга тапшырган вакыттан алып 15 елга кадәр бирелергә мөмкин.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 11 декабрь
№ 88-ТРЗ

Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2021 елның 25 ноябрендә кабул ителде

1 статья

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (1999 елның 6 декабрендәге 2486 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11–12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 2 (2); 2001, № 12; 2004, № 7 (I өлеш); 2005, № 4 (I өлеш); 2008, № 3; 2009, № 9 – 10; 2012, № 1, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2014, № 1–2, № 4, № 5, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 60 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 94 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяның алтынчы абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 25 статьяның икенче өлешендә «тау эшләрен күзәтүнең дәүләт органы» сүзләрен «федераль дәүләт тау эшләре күзәтчелеге органы» сүзләренә алмаштырырга, «тау эшләрен күзәтүнең югарырак дәүләт органына» сүзләрен «федераль дәүләт тау эшләре күзәтчелегенең югарырак органына» сүзләренә алмаштырырга;

3) 91 статьяның бишенче өлешендә «тау эшләрен күзәтүнең дәүләт органы» сүзләрен «федераль дәүләт тау эшләре күзәтчелеге органы» сүзләренә алмаштырырга;

4) 93 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«93 статья. **Региональ дәүләт геология контроле (күзәтчелеге)**

Региональ дәүләт геология контроле (күзәтчелеге), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган нигезләмәгә таянып, вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата региональ дәүләт геология контроленең (күзәтчелегенең) предметы җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законында, Россия Федерациясе Су кодексында (җир асты су объектларын саклауга таләпләр өлешендә), Россия Федерациясе Салым кодексында (файдалы казылмалар һәм җир асты су объектларын чыгарганда югалтулар нормативлары өлешендә) һәм алар нигезендә кабул ителә торган Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салу буенча вәкаләтләр чикләрендә кабул ителгән Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең, шулай ук җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияләрдә һәм күрсәтелгән норматив хокукый актларда каралган башка рөхсәт документларында булган таләпләрнең оешмалар һәм гражданнар тарафыннан үтәлешеннән гыйбарәт.

Үтәлеше региональ дәүләт геология контроле (күзәтчелеге) кысаларында бәяләнә торган мәҗбүри таләпләр кертелгән рөхсәт документларының исемлеге региональ дәүләт геология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәдә күрсәтелә.

Региональ дәүләт геология контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон белән җайга салына.»;

5) 95 статьяның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт геология контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру;»;

б) 97 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«97 статья. **Федераль дәүләт тау эшләре күзәтчелеге**

Федераль дәүләт тау эшләре күзәтчелеге Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.».

2 статья

«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» 1993 елның 13 июлендәге 1934-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 19 июлендәге 89-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 6 – 7; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 7 – 8; 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 1; 2011, № 11 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлекнең исемендә «. Җитештерү ветеринария хезмәте. Хосусый ветеринария эшчәнлеге» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 10 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 14 статьяның 2 өлешендә «күзәтчелеген» сүзен «контролен (күзәтчелеген)» сүзләренә алмаштырырга;

4) 15 статьяның 4 өлешендә «күзәтчелеген» сүзен «контролен (күзәтчелеген)» сүзләренә алмаштырырга;

5) 17 статьяның 5 өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

3 статья

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяда түбәндәге эчтәлекле 11 өлеш өстәргә:

«11. Эшкуарлык эшчәнлеген һәм башка икътисадый эшчәнлекне башкаруга бәйле һәм үтәлешен бәяләү муниципаль контроль, административ җаваплылыкка тарту, лицензияләр һәм башка рөхсәтләр бирү, аккредитацияләү, бәяләүнең һәм экспертизаның башка рәвешләре кысаларында гамәлгә ашырыла торган муниципаль норматив хокукый актларда булган мәҗбүри таләпләрне (алга таба – мәҗбүри таләпләр) билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү тәртибе, «Россия Федерациясендә мәҗбүри таләпләр турында» 2020 елның 31 июлендәге 247-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү принципларын исәпкә алып, муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнә.»;

2) 6^1 статьяда:

а) исемдә «Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычларны билгеләүче яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны» сүзләрен «Эшкуарлык эшчәнлеге һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен яңа мәҗбүри таләпләрне, инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычларны билгеләүче яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны, мәҗбүри таләпләрне» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү эшкуарлык эшчәнлеге һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен кирәгеннән артык бурычлар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә китерә торган нигезләмәләрне, шулай ук эшкуарлык эшчәнлеге һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектларының һәм җирле бюджетларның нигезләнмәгән чыгымнары барлыкка килүенә китерә торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында уздырыла.»;

в) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль норматив хокукый акт проектының җайга салу йогынтысын бәяләү нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органы (җирле үзидарә органының вазыйфаи заты) тарафыннан бәяләмә әзерләнә, анда муниципаль норматив хокукый акт проектында эшкуарлык эшчәнлеге һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен кирәгеннән артык бурычлар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә китерә торган нигезләмәләрнең, шулай ук эшкуарлык эшчәнлеге һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектларының һәм җирле бюджетларның нигезләнмәгән чыгымнары барлыкка килүенә китерә торган нигезләмәләрнең булуы (булмавы) турында нәтиҗә ясалырга тиеш.»;

3) 6^3 статьяда:

а) 1 өлештә «Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычлар билгели торган яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны» сүзләрен «Эшкуарлык эшчәнлеге һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен яңа мәҗбүри таләпләр, инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычлар билгели торган яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган мәҗбүри таләпләрне, бурычларны» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычлар билгели торган яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны» сүзләрен «эшкуарлык эшчәнлеге һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен яңа мәҗбүри таләпләр, инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычлар билгели торган яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган мәҗбүри таләпләрне, бурычларны» сүзләренә алмаштырырга;

4) 15 статьяда:

а) 1 өлештә:

4^1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4^1) бердәм җылылык белән тәэмин итү оешмасы тарафыннан җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча йөкләмәләрне үтәүгә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;»;

5 пунктта «җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына» сүзләрен «автомобиль транспортына, шәһәр җир өсте электр транспортына һәм юл хуҗалыгына» сүзләренә алмаштырырга;

19 пунктта «аларның үтәлешен тикшереп тору» сүзләрен «төзекләндерү өлкәсендә предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү таләпләренең үтәлешеннән гыйбарәт муниципаль контрольне гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга;

27 пунктта «территорияләреннән файдалану һәм аларны саклау» сүзләрен «территорияләрен саклау һәм алардан файдалану» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлешнең 9 пунктында «аларның үтәлешен тикшереп тору» сүзләрен «төзекләндерү өлкәсендә предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү таләпләренең үтәлешеннән гыйбарәт муниципаль контрольне гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга;

5) 16 статьяның 1 өлешендә:

а) 5 пунктта «җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына» сүзләрен «автомобиль транспортына, шәһәр җир өсте электр транспортына һәм юл хуҗалыгына» сүзләренә алмаштырырга;

б) 22 пунктта «территорияләреннән файдалану һәм аларны саклау» сүзләрен «территорияләрен саклау һәм алардан файдалану» сүзләренә алмаштырырга;

б) 17 статьяның 1 өлешендә:

а) 4^1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4^1) бердәм җылылык белән тәэмин итү оешмасы тарафыннан җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча йөкләмәләрне үтәүгә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;»;

б) 5 пунктта «җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына» сүзләрен «автомобиль транспортына, шәһәр җир өсте электр транспортына һәм юл хуҗалыгына» сүзләренә алмаштырырга;

в) 25 пунктта «аларның үтәлешен тикшереп тору» сүзләрен «төзекләндерү өлкәсендә предметы шәһәр округы территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, шул исәптән социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү таләпләренең үтәлешеннән гыйбарәт муниципаль контрольне гамәлгә ашыру (төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтеп тору (куркынычсызлык мониторингы) барышында ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларның ачыкланганнарын бетерү турында күрсәтмә бирелергә мөмкин)» сүзләренә алмаштырырга;

г) 30 пунктта «территорияләреннән файдалану һәм аларны саклау» сүзләрен «территорияләрен саклау һәм алардан файдалану» сүзләренә алмаштырырга;

7) 1 кушымтаның исемендә «Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычлар билгели торган яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны» сүзләрен «Эшкуарлык эшчәнлеге һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен яңа мәҗбүри таләпләр, инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычлар билгели торган яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган мәҗбүри таләпләрне, бурычларны» сүзләренә алмаштырырга.

4 статья

«Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 11; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 3, № 9; 2013, № 4 (I өлеш); 2014, № 3; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяда:

а) беренче өлештәге егерме икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә региональ дәүләт күзәтчелеге турында нигезләмәне, җирле үзидарә органнары тарафыннан халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга дәүләт күзәтчелеге тәртибен раслау;»;

б) икенче өлештәге беренче җөмләдә «икенче – егерме өченче абзацларында» сүзләрен «икенче – егерме беренче, егерме өченче абзацларында» сүзләренә алмаштырырга, икенче җөмләдә «беренче өлешендәге» сүзләреннән соң «егерме икенче,» сүзләрен өстәргә;

2) 12 статьяда «билгеләнгән тәртиптә» сүзләрен «раслана торган нигезләмә нигезендә» сүзләренә алмаштырырга.

3) 21 статьяның беренче өлешендә «муниципаль берәмлекләр» сүзләреннән соң «, оешмалар» сүзен өстәргә.

5 статья

Татарстан Республикасы Җир кодексының 44 статьясындагы 2 пунктында (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2021 елның 9 ноябре) «дәүләт җир күзәтчелеге» сүзләрен «федераль дәүләт җир контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга.

6 статья

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2015 елның 2 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендә «күзәтчелеген» сүзен «контролен (күзәтчелеген)» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 статьяның 3 өлешендәге 3 пунктында «күзәтчелеген» сүзен «контролен (күзәтчелеген)» сүзләренә алмаштырырга;

3) 4 статьяның 2 өлешендәге 2 пунктында «күзәтчелеген» сүзен «контролен (күзәтчелеген)» сүзләренә алмаштырырга.

7 статья

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында» 2005 елның 8 апрелендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш); № 7 – 8) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешнең 11 пунктында «җир асты байлыкларын геологик өйрәнүгә, саклауга һәм нәтиҗәле файдалануга дәүләт контролен» сүзләрен «региональ дәүләт геология контролен (күзәтчелеген)» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 өлештә «1 пунктында» сүзләрен «1 өлешендә» сүзләренә алмаштырырга.

8 статья

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 1, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 өлешнең 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау һәм торгызу өлкәсендәге органының федераль дәүләт урман контролен (урман күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген, урманнарны саклауны гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген һәм урманнарда федераль дәүләт янгын күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү;

2) 3 өлештә:

а) 13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13) урман фонды җирләрендә федераль дәүләт урман контролен (урман күзәтчелеген), урманнарны саклауны, шулай ук, Россия Федерациясе Урман кодексының 68 статьясындагы 1 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында каралган очраклардан тыш, урман фонды җирләрендә урман төзелешен гамәлгә ашыру;»;

б) түбәндәге эчтәлекле 13^{10} пункт өстәргә:

«13^{10}) вәкаләтле орган ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләренең федераль дәүләт урман контролен (урман күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген билгеләү;».

9 статья

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяның 1 өлешендә:

а) алтынчы абзацта «күзәтчелеген» сүзен «контролен (күзәтчелеген)» сүзләренә алмаштырырга;

б) егерме дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау һәм торгызу өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген, урманнарны саклауны гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген һәм урманнарда федераль дәүләт янгын күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү;»;

в) егерме сигезенче абзацта «күзәтчелегендә» сүзен «контролендә (күзәтчелегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

г) егерме тугызынчы абзацта «күзәтчелегендә» сүзен «контролендә (күзәтчелегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

2) VII бүлек исемендә «күзәтчелеге» сүзен «контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга»;

3) 45 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«45 статья. **Региональ дәүләт экология контроле (күзәтчелеге)**

Региональ дәүләт экология контроле (күзәтчелеге), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасының вәкаләтле башкарма хакимият органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

4) 46 статьяда:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«46 статья. **Региональ дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) органнары вазыйфаи затларының хокуклары»;**

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Региональ дәүләт экология контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органнарның әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә дәүләт инспекторлары булып торучы вазыйфаи затлары, контроль (күзәтчелек) чаралар уздыру барышында һәм аларның йомгаклары буенча кабул ителә торган «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән карарлар белән берлектә, бирелгән компетенцияләре чикләрендә, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә түбәндәге хокукларга ия:

1) әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә законнар бозуга бәйле материалларны, җинаять эшләре кузгату турындагы мәсьәләне хәл итү өчен, вәкаләтле органнарга җибәрү;

2) мәҗбүри таләпләрне бозу аркасында әйләнә-тирә мохиткә һәм аның компонентларына китерелгән зыянны түләттерү турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә дәгъва белдерү.»;

в) 2 өлештә «Дәүләт күзәтчелеге» сүзләрен «Региональ дәүләт экология контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;»

5) 89 статьяның 2 өлешендә «атмосфера һавасын саклау өлкәсендә региональ дәүләт экология күзәтчелеген» сүзләрен «региональ дәүләт экология контролен (күзәтчелеген)» сүзләренә алмаштырырга;

6) 120 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«120 статья. **Федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге)**

Федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан, аларга Россия Федерациясенең федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру вәкаләтләре тапшырылган очракта, башкарыла.»;

7) 122 статьяның 1 өлешендә «хайваннар дөньясы объектларын саклау, торгызу һәм алардан файдалану өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеге» сүзләрен «хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау, торгызу һәм алардан файдалану өлкәсендә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

8) 124 статьяның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау, торгызу һәм алардан файдалану өлкәсендә мәҗбүри таләпләр билгеләү һәм аларның үтәлешенә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге);»;

9) 135^6 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«135^6 статья. **Федераль дәүләт аучылык контроле (күзәтчелеге)**

Федераль дәүләт аучылык контроле (күзәтчелеге) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан, аларга Россия Федерациясенең федераль дәүләт аучылык контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру вәкаләтләре тапшырылган очракта, башкарыла.»;

10) 141 статьяның тугызынчы абзацында «дәүләт тау эшләре күзәтчелеге органы һәм җир асты байлыкларын геологик өйрәнүгә, алардан нәтиҗәле файдалануга һәм аларны саклауга дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы орган» сүзләрен «федераль дәүләт тау эшләре күзәтчелеге органы һәм дәүләт геология контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органнар» сүзләренә алмаштырырга;

11) 145 статьяның 1 өлешендә «күзәтчелегенең» сүзен «контроленең (күзәтчелегенең)» сүзләренә алмаштырырга;

12) 167 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«167 статья. **Калдыклар белән эш итү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләү**

Калдыклар белән эш итү өлкәсендә «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль законда һәм аңа нигезләнеп кабул ителә торган башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең (үтәлешен бәяләү каты коммуналь калдыклар белән эш итү тармагында тарифларны җайга салу өлкәсендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында үткәрелә торган мәҗбүри таләпләрдән тыш) үтәлешен бәяләү «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә федераль дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) һәм региональ дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) кысаларында уздырыла.».

10 статья

«Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында» 2010 елның 14 октябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 4; 2018, № 78 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 1 пунктында «Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей әйберләренә һәм музей тупланмаларына карата» сүзләрен «Россия Федерациясе Музей фонды торышына» сүзләренә алмаштырырга, «дәүләт тикшереп торуын» сүзләрен «региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген)» сүзләренә алмаштырырга;

2) 10 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10 статья. **Россия Федерациясе Музей фонды торышына региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге)**

1. Россия Федерациясе Музей фонды торышына региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый торган нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә дәүләт җайга салуын гамәлгә ашыруга вәкаләтле органы тарафыннан башкарыла.

2. Россия Федерациясе Музей фонды торышына региональ дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) предметы музей предметлары һәм музей коллекцияләре милек хокукында, оператив идарәдә яисә куллануда булган Татарстан Республикасы карамагындагы дәүләт музейлары тарафыннан Россия Федерациясе музей фондының дәүләт өлеше составына кертелгән музей предметларын һәм музей коллекцияләрен саклауны, өйрәнүне, туплауны, исәпкә алуны һәм куллануны тәэмин итүгә карата Федераль законда һәм аның нигезендә кабул ителә торган башка норматив хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең үтәлешеннән гыйбарәт.».

11 статья

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2^1 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 77 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле 6^1 һәм 6^2 пунктлар өстәп, үзгәреш кертергә:

«6^1) региональ дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыра торган вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органын билгеләү;

6^2) региональ дәүләт төзелеш күзәтчелеге турында нигезләмәне раслау;».

12 статья

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:

а) 1 өлештә «республика дәүләт торак күзәтчелеген» сүзләрен «региональ дәүләт торак контролен (күзәтчелеген) (алга таба – региональ дәүләт торак күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга, «һәм муниципаль торак контролен» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

2) 4 статьяда:

а) 2 пунктта «республика» сүзен «региональ» сүзенә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 2^2 пункт өстәргә:

«2^2) региональ дәүләт торак күзәтчелеге турында нигезләмәне раслау;»;

3) 5 статьяда:

а) 1 өлештә «республика» сүзен «региональ» сүзенә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «итү» сүзеннән соң «буенча эшкуарлык» сүзләрен өстәргә, «бирә» сүзен «бирүне, шулай ук күпфатирлы йортларга идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген башкаруга региональ дәүләт лицензия контролен гамәлгә ашыра» сүзләренә алмаштырырга;

4) 6^1 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

5) 6^2 статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

13 статья

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 3, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 26 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«26 статья. **Сәламәтлек саклау өлкәсендә контроль (күзәтчелек), шулай ук аны гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар**

1. Сәламәтлек саклау өлкәсендә контроль (күзәтчелек) Федераль законның 85 статьясында билгеләнгән контроль (күзәтчелек) төрләре аша гамәлгә ашырыла.

2. Федераль законда билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә контрольне (күзәтчелекне) гамәлгә ашыручы вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы булып Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы тора.»;

2) 27 статьяда:

а) исемдә «контролен» сүзеннән соң «(күзәтчелеген)» сүзен өстәргә;

б) 1 өлештә:

беренче абзацта «контроле» сүзеннән соң «(күзәтчелеге)» сүзен өстәргә;

7 пунктта «контролен» сүзеннән соң «(күзәтчелеген)» сүзен өстәргә;

в) 2 өлештә:

беренче абзацта «контроле» сүзеннән соң «(күзәтчелеге)» сүзен өстәргә;

1 пунктта «контрольне» сүзеннән соң «(күзәтчелекне)» сүзен өстәргә;

2 пунктта «контроле» сүзеннән соң «(күзәтчелеге)» сүзен өстәргә;

3 пунктта «контроле» сүзеннән соң «(күзәтчелеге)» сүзен өстәргә;

7 пунктта «контролен» сүзеннән соң «(күзәтчелеген)» сүзен өстәргә;

г) 3 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

3) 28 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

4) 29 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы үзенә ведомство буйсынуындагы органнарның һәм оешмаларның медицина эшчәнлеге сыйфатына һәм иминлегенә, Федераль законның 87 статьясындагы 3 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында каралган вәкаләтләрне башкару юлы белән, ведомство контролен гамәлгә ашыра, бу контрольнең төп предметы Федераль законның 87 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктындагы «а» – «в», «д», «е» һәм «з» пунктчаларында һәм Федераль законның 95 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән мәҗбүри таләпләрнең (медицина оешмаларының медицина әйберләрен куллануга һәм эксплуатацияләүгә һәм аларны утильләштерүгә (юкка чыгаруга) таләпләрне үтәве өлешендә) үтәлешеннән гыйбарәт.».

14 статья

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 16 статьяда:

а) 3 өлештә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Мәгариф системасына мониторинг кысаларында аккредитация мониторингы гамәлгә ашырыла, аның төп предметы белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан аккредитация күрсәткечләрен үтәүне системалы рәвештә стандартлаштырылган күзәтеп торудан гыйбарәт.»;

б) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Федераль закон нигезендә мәгариф системасына мониторинг үткәрү тәртибе, шулай ук мониторинг үтәргә тиешле мәҗбүри мәгълүмат исемлеге, аккредитация мониторингын үткәрү һәм аның нәтиҗәләрен куллану тәртибен дә кертеп, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.»;

2) 19 статьяның 2 өлешендә «шулай ук аспирантурада (адъюнктурада) фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары нигезендә белем бирү өчен фәнни белгечлекләр буенча» сүзләрен «шулай ук аспирантурада (адъюнктурада) фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары нигезендә белем бирү өчен фәнни белгечлекләр төркемнәре һәм (яисә) фәнни белгечлекләр буенча» сүзләренә алмаштырырга, «әгәр

әлеге статьяда башкасы билгеләнмәгән булса» сүзләрен «әгәр Федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса» сүзләренә алмаштырырга.

15 статья

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) турында нигезләмәне раслау;»;

2) 5 статьяның 2 өлешендәге 2 пунктында «республика» сүзен «региональ» сүзенә алмаштырырга;

3) түбәндәге эчтәлекле 5^2 статья өстәргә:

«5^2 статья. **Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметы**

Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә региональ дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) предметы дәүләтнеке булмаган (коммерциячел һәм коммерциягә карамаган) социаль хезмәт күрсәтү оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы индивидуаль эшкуарлар санынннан булган социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр тарафыннан «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» Федераль закон, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, шулай ук әлеге Закон һәм социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хокукый мөнәсәбәтләрне җайга сала торган башка Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләренең үтәлешеннән гыйбарәт.».

16 статья

«Татарстан Республикасында азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүнең аерым чаралары турында» 2016 елның 17 ноябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 6 пунктында (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 51 (I өлеш) «күзәтчелеген» сүзен «контролен (күзәтчелеген)» сүзләренә алмаштырырга.

17 статья

«Татарстан Республикасында социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында» 2017 елның 23 июнендәге 41-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 50 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«8 статья. **Социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләү**

Социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү, шулай ук аларга бу очракта кирәкле ярдәм күрсәтү максатларында кабул ителгән Федераль закон, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары таләпләрен үтәү Федераль законның 15^1 статьясы нигезләмәләре нигезендә тәэмин ителә.».

18 статья

«Татарстан Республикасында архив эше турында» 2017 елның 20 июлендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяда түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәргә:

«7) архив эше турында законнар үтәлешенә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) турында нигезләмәне раслау.»;

2) 6 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый торган нигезләмәгә таянып, архив эше турында законнар үтәлешенә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге);»;

3) 17 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17 статья. **Архив эше турында законнар үтәлешенә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге)**

1. Архив эше турында законнар үтәлешенә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) архив эше өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Архив эше турында законнар үтәлешенә региональ дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) предметы Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе Архив фонды документлары һәм башка архив документлары саклауны, туплауны, исәпкә алуны һәм алардан файдалануны оештыруга федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең үтәлешеннән гыйбарәт.».

19 статья

«Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2019 елның 27 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 4 (I өлеш), № 26 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешнең 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) турында нигезләмәне раслау;»;

2) 2 өлештә түбәндәге эчтәлекле 1^1 пункт өстәргә:

«1^1) хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру;»;

3) 3 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

20 статья

Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» 1996 елның 28 мартындагы 482 номерлы Татарстан Республикасы Законының 6^1 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 4; 2002, № 12 (II өлеш); 2003, № 6; 2005, № 12 (I өлеш); 2007, № 4; 2009, № 1; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш);

2) «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» 2006 елның 20 июнендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 өлешенең уникенче абзацын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2012, № 3, № 7 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 2 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш);

3) «Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында» 2012 елның 14 июлендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 4 өлешенең 4 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 7 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 83 (I өлеш).

21 статья

1. Әлеге Закон, бу Законның 12 статьясындагы 3 пунктыннан һәм 14 статьясындагы 1 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 12 статьясындагы 3 пункты һәм 14 статьясындагы 1 пункты 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 11 декабрь
№ 89-ТРЗ

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2021 елның 25 ноябрендә кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяга түбәндәге эчтәлекле 6^4 өлеш өстәргә:

«6^4. «Экстремистлык эшчәнлегенә каршы тору турында» 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы Федераль законда йә «Террорчылыкка каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль законда каралган нигезләр буенча иҗтимагый яисә дини берләшмәне, башка оешманы бетерү яисә аларның эшчәнлеген тыю турында суд карары (алга таба – экстремистлык яисә террорчылык оешмасын бетерү яисә аның эшчәнлеген тыю турында суд карары) законлы көченә кергән иҗтимагый яисә дини берләшмә, башка оешма эшчәнлегенә катнашы булган Россия Федерациясе гражданнарының сайлану хокукы юк.

Әлеге чикләү экстремистлык яисә террорчылык оешмасының гамәлгә куючысы, коллегиаль җитәкче органы әгъзасы, җитәкчесе, җитәкче урынбасары, региональ яки башка структур бүлекчәсе җитәкчесе, региональ яки башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары, катнашучысы, әгъзасы, хезмәткәре яисә экстремистлык яисә террорчылык оешмасы эшчәнлегенә катнашы булган башка зат булып торган затларга экстремистлык яисә террорчылык оешмасын бетерү яисә аның эшчәнлеген тыю турында суд карары законлы көченә кергән көнгә кадәр өч елдан алда башлана торган срокта – экстремистлык яисә террорчылык оешмасының гамәлгә куючысы, коллегиаль җитәкче органы әгъзасы, җитәкчесе, җитәкче урынбасары, региональ яки башка структур бүлекчәсе җитәкчесе, региональ яки башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасарына, экстремистлык яисә террорчылык оешмасын бетерү яисә аның эшчәнлеген тыю турындагы суд карары законлы көченә кергән көнгә кадәр бер елдан алда башлана торган срокта – аның катнашучысы, әгъзасы, хезмәткәренә һәм экстремистлык яисә террорчылык оешмасы эшчәнлегенә катнашы булган башка затына, шулай ук күрсәтелгән суд карары законлы көченә кергәннән соң кагыла.

Әлеге өлеш нигезләмәләре экстремистлык яисә террорчылык оешмасы катнашучыларына, әгъзаларына, хезмәткәрләренә һәм законлы көченә кергән суд карары белән гамәлләрендә экстремистлык яисә террорчылык оешмасы эшчәнлегенә түбәндәге катнашы билгеләнгән башка затларга кагыла: тиешле оешманы экстремистлык яисә террорчылык оешмасы дип тану өчен сәбәп булган эшчәнлек максатларын һәм (яисә) рәвешләрен (шул исәптән аерым чараларны) турыдан-туры гамәлгә ашыру һәм (яисә) тиешле оешманы экстремистлык яисә террорчылык оешмасы дип тану өчен сәбәп булган эшчәнлек максатларын һәм (яисә) рәвешләрен (шул исәптән аерым чараларны) хуплавын сүзләр белән, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге гыйбарәләрне дә кертеп, йә башка гамәлләр аша (акчалата, мөлкәти, оештыру-методик, консультатив яисә башка ярдәм күрсәтү) белдерү.

Экстремистлык яисә террорчылык оешмасының гамәлгә куючысы, коллегиаль җитәкче органы әгъзасы, җитәкчесе, җитәкче урынбасары, региональ яисә башка структур бүлекчәсе җитәкчесе, региональ яисә башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары булган затлар экстремистлык яисә террорчылык оешмасын бетерү яки аның эшчәнлеген тыю турындагы суд карары законлы көченә кергән көннән алып биш ел узганчы сайлана алмыйлар.

Экстремистлык яисә террорчылык оешмасының катнашучысы, әгъзасы, хезмәткәре яисә экстремистлык яисә террорчылык оешмасы эшчәнлегенә катнашы булган башка зат булган затлар экстремистлык яисә террорчылык оешмасын бетерү яисә эшчәнлеген тыю турындагы суд карары законлы көченә кергән көннән алып өч ел узганчы сайлана алмыйлар.»;

2) 12 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле 8^1 өлеш өстәргә:

«8^1. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда каралганча, әлеге статьяның 8 өлеше нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тәкъдиме буенча билгеләнгән Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы вәкаләтләре комиссиянең шушы әгъзасын билгеләп куйган органга кертелгән Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенең дәлилләнгән тәкъдиме буенча вакытыннан алда туктатылырга мөмкин. Комиссия әгъзасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турындагы тәкъдим белән бергә комиссиянең яңа әгъзасы кандидатурасы буенча тәкъдим дә кертелергә тиеш. Мондый тәкъдим булмаса, комиссия әгъзасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында тәкъдим каралмый. Күрсәтелгән тәкъдим комиссия әгъзасы билгеләнгәннән соң бер ел эчендә, шулай ук Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе катнаша торган сайлау кампаниясе чорында, референдум кампаниясе чорында кертелә алмый.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 10^2 өлеш өстәргә:

«10^2. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар уздырганда, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә массакүләм мәгълүмат чаралары, массакүләм коммуникацияләр, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органына сайлаулар һәм референдумнар турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозып әзерләнгән һәм (яисә) таратыла торган агитация материалларының, сайлаулар һәм референдумнар турында Россия Федерациясе законнарын бозып таратыла торган мәгълүматның мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, шул исәптән «Интернет» челтәрендә, таралуын булдырмый калу турында тәкъдим белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, җирле үзидарә органнарына сайлаулар уздырганда, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә массакүләм мәгълүмат чаралары, массакүләм коммуникацияләр, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органына, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе тарафыннан җибәрелгән материалларга нигезләнеп, шундый тәкъдим белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.»;

3) 18 статьяда:

а) 6^2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тәкъдиме буенча билгеләнгән Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә кертелгән Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенең дәлилләнгән тәкъдименә нигезләнеп, үз вәкаләтләре чоры тәмамланганчы, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы вазыйфаларыннан азат ителергә мөмкин.»;

б) 10^1 өлешнең беренче җөмләсендә «сәяси партия тарафыннан» сүзләрен төшереп калдырырга, «әлеге Кодексның 11 статьясындагы 4^2 өлеше нигезендә» сүзләрен «әлеге Кодексның 11 статьясындагы 4^2 өлеше яисә 12 статьясындагы 8^1 өлеше нигезендә» сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату турында тәкъдим кертелгән, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасын билгеләп куйган орган әлеге өлеш нигезендә кабул ителгән карар турында Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә хәбәр итә.»;

4) 39 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

«4) әгәр кандидат чит ил агенты функциясен башкаручы физик зат яисә чит ил агенты функциясен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат булса, – бу хакта белешмәләр.»;

5) 44 статьяның 7 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әгәр кандидат чит ил агенты функциясен башкаручы физик зат яисә чит ил агенты функциясен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат булса, бу хакта белешмәләр имза кәгазендә күрсәтелгән булырга тиеш. Составында шундый кандидат күрсәтелгән кандидатлар исемлеген күрсәтүне хуплап имзалар җыю очрагында, имза кәгазендә әлеге сайлау берләшмәсе тарафыннан чит ил агенты функциясен башкаручы кандидат (кандидатлар) һәм (яисә) чит ил агенты функциясен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат (кандидатлар) күрсәтелү турындагы мәгълүмат бирелә.»;

6) 45 статьяның 3 өлешендәге 4 пунктының «$е^1$» пунктчасында «2 статьясындагы» сүзләрен «3 статьясындагы» сүзләренә алмаштырырга, «2012 елның 3 декабрендәге 229-ФЗ номерлы» сүзләрен «2020 елның 22 декабрендәге 439-ФЗ номерлы» сүзләренә алмаштырырга, «3 өлешендәге» сүзләрен «4 өлешендәге» сүзләренә алмаштырырга;

7) 46 статьяның 5 өлешенә «белешмәләрне» сүзеннән соң «, шул исәптән кандидатның чит ил агенты функциясен башкаручы физик зат йә чит ил агенты функциясен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат булуы турындагы белешмәләрне,» сүзләрен өстәргә;

8) 55 статьяга түбәндәге эчтәлекле 5^1 өлеш өстәргә:

«5^1. Комиссияләр, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларын чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар, челтәр басмалары редакцияләре сайлаучыларга чит ил агенты функциясен башкаручы физик зат булып торучы кандидат турында йә чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат турында хәбәр иткәндә, кандидатның чит ил агенты функциясен башкаручы физик зат яисә чит ил агенты функциясен башкаручы кандидат белән аффилиацияләнгән кандидат булуы күрсәтелергә тиеш.»;

9) 58 статьяда:

а) 4 өлешнең 3 пунктында «бастырып чыгару һәм тарату юлы белән» сүзләрен «эшләү һәм тарату юлы белән, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, «Интернет» челтәрен дә кертеп» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 41 өлеш өстәргә:

«4^1. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда каралганча, агитация материалларын эшләү һәм (яисә) тарату үзенчәлекләре, сайлаулар һәм референдумнар турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнергә мөмкин.»;

в) түбәндәге эчтәлекле 10^3 өлеш өстәргә:

«10^3. Чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат булып торган кандидатның, чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидатның агитация материалында әлеге кандидатның чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат йә чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат булуы турында мәгълүмат булырга тиеш. Тиешле сайлауларда чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат йә чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат булып торган кандидатны күрсәткән (шул исәптән кандидатлар исемлеге составында) сайлау берләшмәсенең агитация материалында сайлау берләшмәсе тарафыннан мондый кандидат күрсәтелү (шул исәптән кандидатлар исемлеге составында) турында мәгълүмат булырга тиеш. Әлеге мәгълүмат ачыктан-ачык күренеп торырга (аңлаешлы ишетелергә) һәм агитация материалы мәйданының (күләменең) кимендә 15 процентын биләргә тиеш.»;

10) 59 статьяда:

а) 1 өлештә «сәгатендә» сүзеннән соң «, ә әлеге Кодексның 75^1 статьясындагы 1 яисә 2 өлешендә каралган тавыш бирүне берничә көн рәттән үткәрү турындагы карар кабул ителгән очракта – тавыш бирүнең беренче көненең җирле вакыт белән ноль сәгатендә» сүзләрен өстәргә;

б) 2 өлештә «сәгатендә» сүзеннән соң «, ә әлеге Кодексның 75^1 статьясындагы 1 яисә 2 өлешендә каралган тавыш бирүне берничә көн рәттән үткәрү турындагы карар кабул ителгән очракта – тавыш бирүнең беренче көненең җирле вакыт белән ноль сәгатендә» сүзләрен өстәргә;

в) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Тавыш бирү көнендә сайлау алды агитациясен үткәрү тыела.

Әлеге Кодексның 75^1 статьясындагы 1 яисә 2 өлешендә каралган тавыш бирүне берничә көн рәттән үткәрү турындагы карар кабул ителү очрагыннан тыш, тавыш бирү көненә кадәрге көндә сайлау алды агитациясен үткәрү тыела.»;

11) 61 статьяның 4^1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә: «Уртак агитация чарасында чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат булып торучы теркәлгән кандидат йә чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән теркәлгән кандидат катнашкан очракта, аның чыгышында әлеге кандидатның чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат йә чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат булуы турындагы мәгълүмат әйтелергә (бирелергә) тиеш. Уртак агитация чарасында тиешле сайлауларда чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат йә чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидатны күрсәткән (шул исәптән кандидатлар исемлеге составында) сайлау берләшмәсе тарафыннан күрсәтелгән теркәлгән кандидат катнашкан очракта, аның чыгышында сайлау берләшмәсе тарафыннан мондый кандидат күрсәтелү турында мәгълүмат әйтелергә (бирелергә) тиеш.»;

12) 62 статьяның 12 өлешенә түбәндәге эчтәлекле яңа өченче җөмлә өстәргә: «Чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат булып торучы кандидатның, чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидатның яисә тиешле сайлауларда мондый кандидатны (мондый кандидатларны) күрсәткән (шул исәптән кандидатлар исемлеге составында) сайлау берләшмәсенең вакытлы басма матбугатларда урнаштырыла торган агитация материалларында әлеге Кодексның 58 статьясындагы 10^3 өлеше нигезендә кандидатның чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат булуы йә чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат булуы турында яисә сайлау берләшмәсе тарафыннан мондый кандидат (кандидатлар) күрсәтелү (шул исәптән кандидатлар исемлеге составында) турында мәгълүмат урнаштырылырга тиеш.»;

13) 64 статьяда:

а) исемендә «чыгару» сүзен «эшләү» сүзенә алмаштырырга;

б) 1 өлештә «таратырга» сүзеннән соң «, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, «Интернет» челтәрен дә кертеп,» сүзләрен өстәргә;

в) 3 өлештә «басылып чыгу» сүзләрен «эшләнү» сүзенә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат булып торучы кандидатның, чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидатның, мондый кандидатны тиешле сайлауларда (шул исәптән кандидатлар исемлеге составында) күрсәткән сайлау берләшмәсенең барлык агитация материалларында әлеге Кодексның 58 статьясындагы 10^3 өлеше нигезендә бу хакта мәгълүмат булырга тиеш.»;

г) 4 өлештә «нөсхәләре,» сүзен «нөсхәләре яисә күчермәләре,» сүзләренә алмаштырырга, «яисә нөсхәләре» сүзләрен «, нөсхәләре яисә күчермәләре» сүзләренә алмаштырырга;

д) 7 өлештә «58 статьясындагы 10 өлешендә» сүзләрен «58 статьясындагы 10 һәм 10^3 өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга;

е) 12 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Әлеге статья нигезләмәләре, әлеге Кодексның 61 һәм 62 статьялары нигезендә таратыла торган агитация материалларыннан тыш, басма, аудиовизуаль һәм башка агитация материалларын, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, тарату өчен эшләнгәннәрен һәм таратыла торганнарын, эшләүгә һәм таратуга карата кулланыла.»;

14) 66 статьяның 12 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Сайлауларны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле товарлар, эшләр яисә хезмәтләр күрсәтү сатып алулар тиешле сайлауларны оештыручы комиссия яисә аның карары нигезендә түбәндәге тиешле комиссияләр тарафыннан «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтү сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, ә күрсәтелгән Федераль закон кулланылмый торган мөнәсәбәтләр өлешендә – Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

15) 67 статьяның 14 өлешендәге 14 пунктына «, чит ил агенты функцияләрен башкаручы чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары реестрына мәгълүмат кертелгән Россия юридик затлары» сүзләрен өстәргә;

16) 68 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик затлар исемлегенә кертелгән һәм (яисә) аның турында мәгълүмат чит ил агенты функцияләрен башкаручы чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары реестрына кертелгән граждан иганә керткәндә, мондый граждан түләү документында бу хакта белешмәләр күрсәтә.»;

б) 5 өлештә «дөрес» сүзеннән соң «яисә тулысынча» сүзләрен өстәргә, «законлы» сүзеннән соң «яисә иганәче турында белешмәләрнең тулы» сүзләрен өстәргә;

17) 73 статьяның 4 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Әгәр теркәлгән кандидат, шул исәптән кандидатлар исемлеге составында, чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат йә чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат булып торса, мәгълүмат стендында бу хакта мәгълүмат урнаштырыла.»;

18) 75 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле 8^1 өлеш өстәргә:

«8^1. Бюллетеньгә уннан артык теркәлгән кандидат кертелгән очракта, сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясе, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе белән килештереп, әлеге статьяның 6 өлешендәге 4 һәм 5 пунктларында, 7 өлешендә каралган теркәлгән кандидатларның һәркайсы турында белешмәләрнең (барлык белешмәләрнең йә кайберләренең) бюллетеньдә урнаштырылмавы һәм сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән форма буенча эшләнә торган махсус мәгълүмат материалында күрсәтелүе турында карар кабул итәргә хокуклы. Әлеге мәгълүмат материалы кабинада йә яшерен тавыш бирү өчен махсус җиһазландырылган башка урында һәм (яисә) әлеге Кодексның 73 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән мәгълүмат стендында урнаштырыла.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 9^1 өлеш өстәргә:

«9^1. Бюллетеньгә уннан артык теркәлгән кандидатлар исемлеге кертелгән очракта, сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясе, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе белән килештереп, әлеге статьяның 9 өлешендә күрсәтелгән кандидатларның фамилияләре, исемнәре, атааларының исемнәре бюллетеньдә урнаштырылмый һәм сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясе билгеләгән рәвештә эшләнә торган махсус мәгълүмат материалында күрсәтелә дигән карар кабул итәргә хокуклы. Әлеге мәгълүмат материалы кабинада йә яшерен тавыш бирү өчен махсус җиһазландырылган башка урында һәм (яисә) әлеге Кодексның 73 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән мәгълүмат стендында урнаштырыла.»;

в) түбәндәге эчтәлекле 10^1 өлеш өстәргә:

«10^1. Әгәр сайлау бюллетененә кертелгән теркәлгән кандидат чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат йә чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат булып торса, сайлау бюллетенендә кандидатның чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат яисә чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат булуы турында белешмәләр күрсәтелергә тиеш. Мондый кандидат (кандидатлар) кандидатлар исемлеге составына кертелгән һәм аның (алар) турында белешмәләр әлеге статьяның 9 өлеше нигезендә сайлау бюллетененә кертелмәгән очракта, сайлау бюллетенендә кандидатлар исемлеге составында мондый кандидат (кандидатлар) күрсәтелде дип билгеләнә.»;

19) 77 статьяның 8^1 өлешендәге беренче абзацында «8 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында» сүзләрен «8 өлешендә» сүзләренә алмаштырырга, «1 күчерелмә әрҗәдән» сүзләрен «2 күчерелмә әрҗәдән» сүзләренә алмаштырырга;

20) 1 нче кушымтада:

а) таблицага 3, 4 һәм 5 юллар өстәргә;

б) искәрмәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Искәрмә. Әгәр имза кәгазендә белешмәләре күрсәтелә торган кандидат элек яисә хәзер хөкем ителгән булса, имза кәгазендә кандидатның атасы исеменнән соң кандидатның хөкем ителүе турында белешмәләр күрсәтелә. Әгәр кандидат чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат йә чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат булып торса, имза кәгазендә кандидатның атасы исеменнән соң (кандидат шулай ук элек яисә хәзер хөкем ителгән очракта – хөкем ителүе турында белешмәләрдән соң) кандидатның чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат йә чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат булуы хакында белешмәләр күрсәтелә. Әгәр имза кәгазендә белешмәләре булган кандидат Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 39 статьясындагы 6 өлеше һәм 41 статьясындагы 2 өлеше нигезендә күрсәтелергә ризалыгы турындагы гаризада кайсы сәяси партиягә йә бүтән иҗтимагый берләшмәгә каравын һәм әлеге сәяси партиядәге йә әлеге иҗтимагый берләшмәдәге үзенең статусын күрсәтсә, бу хакта белешмәләр имза кәгазендә кандидатның яшәү урыны турындагы белешмәләрдән соң яисә кандидатның хөкем ителүе турындагы белешмәләрдән соң, ә кандидат чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат йә чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат булып торса, шул хактагы белешмәләрдән соң бирелә. Имза кәгазе бары тик бер яктан гына тутыру өчен эшләнә, һәм анда сайлаучылар имзаларын кую өчен биш юл булырга тиеш.».

2 статья

«Татарстан Республикасы референдумы турында» 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015 № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 17 статьяда:

а) беренче абзацта «Референдум әзерләгәндә» сүзләрен «1. Референдум әзерләгәндә» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 2 пункт өстәргә:

«2. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, референдум уздырганда, Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә массакүләм мәгълүмат чаралары, массакүләм коммуникацияләр, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органына сайлаулар һәм референдумнар турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозып эшләнгән һәм (яисә) таратыла торган агитация материалларының, сайлаулар һәм референдумнар турында Россия Федерациясе законнарын бозып таратыла торган

мәгълүматның мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, шул исәптән «Интернет» челтәрендә, таралуын булдырмый калу турында тәкъдим белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.»;

2) 34 статьяда:

а) 2 пунктның «в» пунктчасында «бастырып чыгару һәм тарату юлы белән» сүзләрен «эшләү һәм тарату юлы белән, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, «Интернет» челтәрен дә кертеп» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 2^1 пункт өстәргә:

«2^1. Федераль законда каралганча, агитация материалларын эшләү һәм (яисә) тарату үзенчәлекләре, сайлаулар һәм референдумнар турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнергә мөмкин.»;

3) 35 статьяда:

а) 1 пунктта «сәгатендә» сүзеннән соң «, ә әлеге Законның 49^1 статьясындагы 1 яисә 2 пунктында каралган тавыш бирүне берничә көн рәттән үткәрү турындагы карар кабул ителгән очракта – тавыш бирүнең беренче көненең җирле вакыт белән ноль сәгатендә» сүзләрен өстәргә;

б) 2 пунктта «сәгатендә» сүзеннән соң «, ә әлеге Законның 49^1 статьясындагы 1 яисә 2 пунктында каралган тавыш бирүне берничә көн рәттән үткәрү турындагы карар кабул ителгән очракта – тавыш бирүнең беренче көненең җирле вакыт белән ноль сәгатендә» сүзләрен өстәргә;

в) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Тавыш бирү көнендә референдум мәсьәләләре буенча агитация үткәрү тыела.

Әлеге Законның 49^1 статьясындагы 1 яисә 2 пунктында каралган тавыш бирүне берничә көн рәттән үткәрү турындагы карар кабул ителү очрагыннан тыш, тавыш бирү көненә кадәрге көндә референдум мәсьәләләре буенча агитация үткәрү тыела.»;

4) 40 статьяда:

а) исемендә «чыгару» сүзен «эшләү» сүзенә алмаштырырга;

б) 1 пунктта «таратырга» сүзеннән соң «, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, «Интернет» челтәрен дә кертеп,» сүзләрен өстәргә;

в) 2 пунктта «бастырып чыгару» сүзләрен «эшләнү» сүзенә алмаштырырга;

г) 3 пунктта «нөсхәләре,» сүзен «нөсхәләре яисә күчермәләре» сүзләренә алмаштырырга, «яисә нөсхәләре» сүзләрен «, нөсхәләре яисә күчермәләре» сүзләренә алмаштырырга;

д) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Әлеге статья нигезләмәләре, әлеге Законның 37 һәм 38 статьялары нигезендә таратыла торган агитация материалларыннан тыш, басма, аудиовизуаль һәм башка агитация материалларын, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, тарату өчен эшләнгәннәрен һәм таратыла торганнарын, эшләүгә һәм таратуга карата кулланыла.»;

5) 43 статьяның 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Референдум әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле товарлар, эшләр яисә хезмәтләр күрсәтү сатып алулар Федераль законда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

6) 44 статьяда:

а) 5 пунктның «о» пунктчасына «, чит ил агенты функцияләрен башкаручы чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары реестрына мәгълүмат кертелгән Россия юридик затлары» сүзләрен өстәргә;

б) 6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик затлар исемлегенә кертелгән һәм (яисә) аның турында мәгълүмат чит ил агенты функцияләрен башкаручы чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары реестрына кертелгән граждан иганә керткәндә, мондый граждан түләү документында бу хакта белешмәләр күрсәтә.»;

в) 8 пунктта «күрсәткән очракта» сүзләрен «күрсәткән һәм белешмәләр дөрес яисә тулы булмаган очракта» сүзләренә алмаштырырга;

7) 51 статьяның 8^1 пунктындагы беренче абзацында «8 пунктындагы «а» һәм «б» пунктчаларында» сүзләрен «8 пунктында» сүзләренә алмаштырырга, «1 күчерелмә әрҗәдән» сүзләрен «2 күчерелмә әрҗәдән» сүзләренә алмаштырырга.

3 статья

«Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (II өлеш); 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 5 (II өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8, № 12; 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 36 статьяда:

а) 2 пунктның «в» пунктчасында «бастырып чыгару һәм тарату юлы белән» сүзләрен «эшләү һәм тарату юлы белән, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, «Интернет» челтәрен дә кертеп» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 2^1 пункт өстәргә:

«2^1. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда каралганча, агитация материалларын эшләү һәм (яисә) тарату үзенчәлекләре, сайлаулар һәм референдумнар турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнергә мөмкин.»;

в) түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәргә:

«11. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, референдум уздырганда, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә массакүләм мәгълүмат чаралары, массакүләм коммуникацияләр, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органына, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе тарафыннан җибәрелгән материалларга нигезләнеп, сайлаулар һәм референдумнар турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозып эшләнгән һәм (яисә) таратыла торган агитация материалларының, сайлаулар һәм референдумнар турында Россия Федерациясе законнарын бозып таратыла торган мәгълүматның мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, шул исәптән «Интернет» челтәрендә, таралуын булдырмый калу турында тәкъдим белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.»;

2) 37 статьяда:

а) 1 пунктта «сәгатендә» сүзеннән соң «, ә әлеге Законның 51^1 статьясындагы 1 яисә 2 пунктында каралган тавыш бирүне берничә көн рәттән үткәрү турындагы карар кабул ителгән очракта – тавыш бирүнең беренче көненең җирле вакыт белән ноль сәгатендә» сүзләрен өстәргә;

б) 2 пунктта «сәгатендә» сүзеннән соң «, ә әлеге Законның 51^1 статьясындагы 1 яисә 2 пунктында каралган тавыш бирүне берничә көн рәттән үткәрү турындагы карар кабул ителгән очракта – тавыш бирүнең беренче көненең җирле вакыт белән ноль сәгатендә» сүзләрен өстәргә;

в) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Тавыш бирү көнендә референдум мәсьәләләре буенча агитация үткәрү тыела.

Әлеге Законның 51^1 статьясындагы 1 яисә 2 пунктында каралган тавыш бирүне берничә көн рәттән үткәрү турындагы карар кабул ителү очрагыннан тыш, тавыш бирү көненә кадәрге көндә референдум мәсьәләләре буенча агитация үткәрү тыела.»;

3) 42 статьяда:

а) исемендә «чыгару» сүзен «эшләү» сүзенә алмаштырырга;

б) 1 пунктта «таратырга» сүзеннән соң «, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, «Интернет» челтәрен дә кертеп,» сүзләрен өстәргә;

в) 2 пунктта «чыгару» сүзен «эшләнү» сүзенә алмаштырырга;

г) 3 пунктта «нөсхәләре,» сүзен «нөсхәләре яисә күчермәләре» сүзләренә алмаштырырга, «яисә нөсхәләре» сүзләрен «, нөсхәләре яисә күчермәләре» сүзләренә алмаштырырга;

д) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Әлеге статья нигезләмәләре, әлеге Законның 39 һәм 40 статьялары нигезендә таратыла торган агитация материалларыннан тыш, басма, аудиовизуаль һәм башка агитация материалларын, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, тарату өчен эшләнгәннәрен һәм таратыла торганнарын, эшләүгә һәм таратуга карата кулланыла.»;

4) 45 статьяның 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Референдум әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле товарлар, эшләр яисә хезмәтләр күрсәтү сатып алулар «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

5) 46 статьяда:

а) 5 пунктның «о» пунктчасына «, чит ил агенты функцияләрен башкаручы чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары реестрына мәгълүмат кертелгән Россия юридик затлары» сүзләрен өстәргә;

б) 6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик затлар исемлегенә кертелгән һәм (яисә) аның турында мәгълүмат чит ил агенты функцияләрен башкаручы чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары реестрына кертелгән граждан иганә керткәндә, мондый граждан түләү документында бу хакта белешмәләр күрсәтә.»;

в) 8 пунктта «белешмәләрне һәм дөрес булмаган белешмәләрне күрсәткән очракта» сүзләрен «белешмәләрне күрсәткән һәм алар дөрес яисә тулы булмаган очракта» сүзләренә алмаштырырга;

6) 53 статьяның 8^1 пунктындагы беренче абзацында «8 пунктындагы «а» һәм «б» пунктчаларында» сүзләрен «8 пунктында» сүзләренә алмаштырырга, «1 күчерелмә әрҗәдән» сүзләрен «2 күчерелмә әрҗәдән» сүзләренә алмаштырырга.

4 статья

«Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алу тәртибе турында» 2012 елның 25 декабрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 18 статьяда:

а) беренче абзацта «Чакыртып алу буенча» сүзләрен «1. Чакыртып алу буенча» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

«2. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздырганда, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә массакүләм мәгълүмат чаралары, массакүләм коммуникацияләр, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органына сайлаулар һәм референдумнар турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозып эшләнгән һәм (яисә) таратыла торган агитация материалларының, сайлаулар һәм референдумнар турында Россия Федерациясе законнарын бозып таратыла торган мәгълүматның мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, шул исәптән «Интернет» челтәрендә, таралуын булдырмый калу турында тәкъдим белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.»;

2) 31 статьяда:

а) 2 өлешнең 3 пунктында «бастырып чыгару һәм тарату юлы белән» сүзләрен «эшләү һәм тарату юлы белән, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, «Интернет» челтәрен дә кертеп» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 2^1 өлеш өстәргә:

«2^1. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда каралганча, агитация материалларын эшләү һәм (яисә) тарату үзенчәлекләре, сайлаулар һәм референдумнар турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнергә мөмкин.»;

3) 32 статьяда:

а) 1 өлештә «сәгатьтә» сүзеннән соң «, ә әлеге Законның 45^1 статьясындагы 1 яисә 2 өлешендә каралган тавыш бирүне берничә көн рәттән үткәрү турындагы карар кабул ителгән очракта – тавыш бирүнең беренче көнендә җирле вакыт белән ноль сәгатьтә» сүзләрен өстәргә;

б) 2 өлештә «сәгатьтә» сүзеннән соң «, ә әлеге Законның 45^1 статьясындагы 1 яисә 2 өлешендә каралган тавыш бирүне берничә көн рәттән үткәрү турындагы карар кабул ителгән очракта – тавыш бирүнең беренче көнендә җирле вакыт белән ноль сәгатьтә» сүзләрен өстәргә;

в) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Тавыш бирү көнендә чакыртып алу мәсьәләләре буенча агитация үткәрү тыела.

Әлеге Законның 45^1 статьясындагы 1 яисә 2 өлешендә каралган тавыш бирүне берничә көн рәттән үткәрү турындагы карар кабул ителү очрагыннан тыш, тавыш бирү көненә кадәрге көндә чакыртып алу мәсьәләләре буенча агитация үткәрү тыела.»;

4) 37 статьяда:

а) исемендә «чыгару» сүзен «эшләү» сүзенә алмаштырырга;

б) 1 өлештә «таратырга» сүзеннән соң «, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, «Интернет» челтәрен дә кертеп,» сүзләрен өстәргә;

в) 3 өлештә «басылып чыгу» сүзләрен «эшләнү» сүзенә алмаштырырга;

г) 4 өлештә «нөсхәләре,» сүзен «нөсхәләре яисә күчермәләре,» сүзләренә алмаштырырга, «яисә нөсхәләре» сүзләрен «, нөсхәләре яисә күчермәләре» сүзләренә алмаштырырга;

д) 11 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Әлеге статья нигезләмәләре, әлеге Законның 34 һәм 35 статьялары нигезендә таратыла торган агитация материалларыннан тыш, басма, аудиовизуаль һәм башка агитация материалларын, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, тарату өчен эшләнгәннәрен һәм таратыла торганнарын, эшләүгә һәм таратуга карата кулланыла.»;

5) 39 статьяның 7 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле товарлар, эшләр яисә хезмәтләр күрсәтү сатып алулар «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

6) 40 статьяда:

а) 5 өлешнең 14 пунктына «, чит ил агенты функцияләрен башкаручы чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары реестрына мәгълүмат кертелгән Россия юридик затлары» сүзләрен өстәргә;

б) 7 өлешкә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик затлар исемлегенә кертелгән һәм (яисә) аның турында мәгълүмат чит ил агенты функцияләрен башкаручы чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары реестрына кертелгән граждан иганә керткәндә, мондый граждан түләү документында бу хакта белешмәләр күрсәтә.»;

в) 9 өлештә «җитәрлек» сүзеннән соң «яисә тулы» сүзләрен өстәргә;

7) 47 статьяның 9 өлешендәге беренче абзацында «8 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында» сүзләрен «8 өлешендә» сүзләренә алмаштырырга, «1 күчерелмә әрҗәдән» сүзләрен «2 күчерелмә әрҗәдән» сүзләренә алмаштырырга.

5 статья

1. Әлеге Закон, бу статьяда үз көченә керүнең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 14 пункты, 2 статьясындагы 5 пункты, 3 статьясындагы 4 пункты һәм 4 статьясындагы 5 пункты 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 11 декабрь
№ 90-ТРЗ

Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2021 елның 25 ноябрендә кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяның 1 өлешендәге утыз сигезенче абзацында «калдыклар исәбе» сүзләреннән соң «федераль» сүзен өстәргә;

2) 93 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Сазлыкларны җитештерү һәм куллану калдыклары белән пычрату һәм чүпләү, аларны нефть продуктлары һәм башка пычраткыч матдәләр, шулай ук пестицидлар белән пычрату тыела.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

«3. Сазлыклардан аерым максатларда файдалану үзенчәлекләре федераль законнар нигезендә билгеләнә.»;

3) 99 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

«3. Махсус сакланылучы аерым су объектларыннан файдалану үзенчәлекләре федераль законнар нигезендә билгеләнә.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 11 декабрь
№ 91-ТРЗ

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2021 елның 25 ноябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 8 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 12 (II өлеш); 2010, № 5 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 3, № 10; 2014, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 92 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), «шулай ук Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән арадаш һәм еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын алу» сүзләрен «шулай ук Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән арадаш бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын һәм Федераль законның 23 статьясындагы 6 өлешенең 6 пунктында билгеләнгән очракта еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын алу» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2 статья

Әлеге Закон 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 11 декабрь
№ 92-ТРЗ

«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2021 елның 25 ноябрендә кабул ителде

1 статья

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 26 февралендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 2; 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 6; 2011, № 5; 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 5; 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 статья. **Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу Россия Федерациясе Конституциясе, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон), башка федераль законнар һәм Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән гамәлгә ашырыла.»;

2) 2 статьяның өченче өлешендәге 9 пунктында «эшләр башкару һәм хезмәт күрсәтүләр» сүзләрен «эшчәнлекне гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга;

3) 4 статьяның унбишенче абзацында «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 14 статьяның өченче өлешендә «янгын куркынычсызлыгы таләпләрен» сүзләрен «янгын куркынычсызлыгының мәҗбүри таләпләрен (алга таба – янгын куркынычсызлыгы таләпләре)» сүзләренә алмаштырырга;

5) 21 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21 статья. **Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә эшчәнлек**

Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә эшчәнлек янгын куркынычсызлыгы таләпләрен гамәлгә ашыру максатларында, шулай ук янгыннарны кисәтү һәм сүндерү максатларында башкарыла. Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләре исемлеге Федераль закон белән билгеләнә.»;

6) 22 статьяда:

а) икенче өлештә «һәм (яисә) янгын-техник минимумы программалары» сүзләрен «программалары, өстәмә һөнәри программалар» сүзләренә алмаштырырга;

б) өченче өлештә «янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү тәртибе, төрләре, сроклары, шулай ук өстәмә һөнәри белем бирү программалары (янгын-техник минимумы программалары) эчтәлегенә карата таләпләр» сүзләрен «янгынга каршы инструктаж программалары буенча өйрәтү тәртибе, төрләре, сроклары, шулай ук күрсәтелгән программалар эчтәлегенә карата таләпләр» сүзләренә алмаштырырга;

в) дүртенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф турында Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла. Өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча белем алучы затларның категорияләре федераль башкарма хакимиятнең янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә мәсьәләләрне хәл итүгә вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 11 декабрь
№ 93-ТРЗ

Татарстан Республикасында умартачылыкны үстерү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2021 елның 25 ноябрендә кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Россия Федерациясендә умартачылык турында» 2020 елның 30 декабрендәге 490-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасында умартачылыкны үстерү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга сала.

2 статья. **Умартачылыкны үстерү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

Умартачылыкны үстерү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу Федераль закон, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, шулай ук җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары белән гамәлгә ашырыла.

3 статья. **Умартачылыкны үстерү өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре**

Умартачылыкны үстерү өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) умартачылыкны үстерү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне законнар белән җайга салу;

2) умартачылыкны үстерү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала торган Татарстан Республикасы законнарын үтәүне һәм башкаруны тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

3) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

4 статья. **Умартачылыкны үстерү өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

1. Умартачылыкны үстерү өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) умартачылыкны үстерүгә юнәлдерелгән чаралар каралган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын раслау;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең умартачылыкны үстерү өлкәсендәге вәкаләтле органын билгеләү;

3) бал кортлары авыруларын кисәтү һәм бетерү һәм аларны дәвалау чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

4) умарталыкның ветеринария-санитария паспортын рәсмиләштерү һәм алып бару тәртибен билгеләү;

5) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән вәкаләтләр турыдан-туры Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан гамәлгә ашырыла. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 3 – 5 пунктларында күрсәтелгән вәкаләтләр турыдан-туры Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан яисә аның тарафыннан вәкаләтләр бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы (органнары) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5 статья. **Умартачылыкны үстерү өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, аларга Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә умартачылыкны үстерү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләре бирелгән очракта, күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар.

6 статья. **Умартачылыкны үстерү өлкәсендә дәүләт ярдәме**

1. Умартачылыкны үстерү өлкәсендә дәүләт ярдәме Федераль законның 9 статьясында каралган юнәлешләр буенча тәэмин ителә һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары чикләрендә күрсәтелә.

2. Умартачылыкны үстерү өлкәсендә дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыру шартлары һәм тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

7 статья. **Умартачылыкны үстерү өлкәсендә дәүләт ярдәме принциплары**

Умартачылыкны үстерү өлкәсендә дәүләт ярдәменең төп принциплары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) умартачылыкны гамәлгә ашыручы физик һәм юридик затларның, дәүләт ярдәме күрсәтүне сорап, гариза белән мөрәҗәгать итү тәртибе;

2) умартачылыкны гамәлгә ашыручы физик һәм юридик затларның дәүләт ярдәменнән бертигез дәрәҗәдә файдалануы;

3) дәүләт ярдәме күрсәтү процедураларының ачык булуы;

4) дәүләт ярдәмен, Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән таләпләрне үтәп, күрсәтү.

8 статья. **«Татарстан Республикасында умартачылыкны дәүләт тарафыннан җайга салу һәм аңа дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану хакында**

«Татарстан Республикасында умартачылыкны дәүләт тарафыннан җайга салу һәм аңа дәүләт ярдәме турында» 2010 елның 22 ноябрендәге 83-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 11) үз көчен югалткан дип танырга.

9 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 11 декабрь
№ 94-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ КАРАРЫ

гражданин А.В. Туганов шикаятенә бәйле рәвештә Зеленодольск шәһәре Советының 2021 елның 24 мартындагы 37 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 35 статьясындагы 1 өлешенең 36 пункты, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 24 мартындагы 61 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 54 статьясындагы 1 өлешенең 4 һәм 5 пунктлары, 11 пунктының унҗиденче абзацы нигезләмәләренең, «Зеленодольск шәһәренең торак фондының торак урыннарын карап тоткан өчен түләү күләме турында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24 декабрендәге 2844 номерлы карарының, шулай ук «Зеленодольск шәһәре торак фондының торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләме турында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 26 ноябрендәге 2270 номерлы карарының конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча

Казан шәһәре 2021 елның 23 ноябре

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Э.М. Мостафина, Г.Л. Удачина, М.М. Хәйруллин составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында гражданин А.В. Туганов шикаятенә бәйле рәвештә Зеленодольск шәһәре Советының 2021 елның 24 мартындагы 37 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 35 статьясындагы 1 өлешенең 36 пункты, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 24 мартындагы 61 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 54 статьясындагы 1 өлешенең 4 һәм 5 пунктлары, 11 пунктының унҗиденче абзацы нигезләмәләренең, «Зеленодольск шәһәренең торак фондының торак урыннарын карап тоткан өчен түләү күләме турында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24 декабрендәге 2844 номерлы карарының, шулай ук «Зеленодольск шәһәре торак фондының торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләме турында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 26 ноябрендәге 2270 номерлы карарының конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданин А.В. Туганов шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шикаять белдерелә торган норматив хокукый нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья Г.Л. Удачина мәгълүматын, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актларны чыгарган органнар вәкилләре — Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының юридик бүлеге башлыгы Э.Ә. Нургалиева, «Зеленодольск муниципаль районының юридик бюросы» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе Н.Н. Пименова аңлатмаларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

билгеләде:

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин А.В. Туганов Зеленодольск шәһәре Советының 2018 елның 29 мартындагы 182 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 35 статьясындагы 1 пунктының 37 пунктчасы, 72 статьясының 3, 9 һәм 12 өлешләре, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2018 елның 29 мартындагы 279 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 52 статьясындагы 1 өлешенең 4 һәм 5 пунктчалары, 11 пунктчасының уналтынчы абзацы, 81 статьясындагы 3, 9 һәм 12 өлешләре, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2015 елның 27 мартындагы 514 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне тапшыру турында килешүләр төзү тәртибенең 5.2 пункты нигезләмәләре белән, шулай ук тулысынча «Зеленодольск шәһәренең торак фондының торак урыннарын карап тоткан өчен түләү күләме турында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24 декабрендәге 2844 номерлы карары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Гражданин А.В. Туганов шикаяте Татарстан Республикасы Конституция судының 2020 елның 30 ноябрендәге 37-О номерлы билгеләмәсе белән карауга алынган иде.

1.1. Суд утырышында эшне карый башлаган вакытка мөрәҗәгать итүче шикаять белдерә торган кайбер хокукый актлар үз көчләрен югалткан, йә үзгәрешләр кичергән:

– Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2018 елның 29 мартындагы 279 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы һәм Зеленодольск шәһәре Советының 2018 елның 29 мартындагы 182 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы тиешенчә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» 2021 елның 24 мартындагы 61 номерлы карары (алга таба шулай ук – Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 24 мартындагы 61 номерлы карары) белән һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» 2021 елның 24 мартындагы 37 номерлы карары (алга таба шулай ук – Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре Советының 2021 елның 24 мартындагы 37 номерлы карары) белән үз көчен югалткан дип танылган;

– Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2020 елның 14 декабрендәге 31 номерлы карары белән Зеленодольск муниципаль районы Советының 2015 елның 27 мартындагы 514 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне тапшыру турында килешүләр төзү тәртибенә үзгәрешләр кертелгән, аерым алганда, 5.2 пункт яңа редакциядә бәян ителгән;

– «Зеленодольск шәһәре торак фондының торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләме турында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 26 ноябрендәге 2270 номерлы карары белән «Зеленодольск шәһәренең торак фондының торак урыннарын карап тоткан өчен түләү күләме турында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24 декабрендәге 2844 номерлы карары үз көчен югалткан дип танылган.

Югарыда аталган үзгәрешләр белән бәйле рәвештә гражданин А.В. Туганов Татарстан Республикасы Конституция судына шикаятькә төгәллек кертү турында сорап мөрәҗәгать итте, анда ул тиешенчә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 24 мартындагы 61 номерлы карары белән расланган һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре Советының 2021 елның 24 мартындагы 37 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставында (алга таба шулай ук – район Уставы) һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставында (алга таба шулай ук – шәһәр Уставы) шикаять белдерелә торган нормаларга охшаш нигезләмәләр бар дип күрсәтә һәм шикаятьтә бәян ителгән нигезләр буенча аларны Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип тануны сорый.

Шул ук вакытта гражданин А.В. Туганов Зеленодольск муниципаль районы Советының 2015 елның 27 мартындагы 514 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне тапшыру турында килешүләр төзү тәртибенең (алга таба шулай ук – Тәртип) 5.2 пунктын үзе Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать иткән вакытта гамәлдә булган редакциясендә карауны таләп итә, чөнки, аның фикеренчә, анда каралган җирле үзидарә органнары арасында килешүләрнең үз көченә керү тәртибе мөрәҗәгать итүченең конституциячел хокукларын һәм ирекләрен бозуга китергән. Моннан тыш, гражданин А.В. Туганов «Зеленодольск шәһәренең торак фондының торак урыннарын карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2019 елның 24 декабрендәге 2844 номерлы үз көчен югалткан карар (алга таба шулай ук – 2019 елның 24 декабрендәге 2844 номерлы карар) белән үз хокуклары бозылган дип саный һәм Татарстан Республикасы Конституция судыннан күрсәтелгән актны, шулай ук хәзерге вакытта гамәлдә булган «Зеленодольск шәһәре торак фондының торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләме турында» 2020 елның 26 ноябрендәге 2270 номерлы карарны (алга таба шулай ук — 2020 елның 26 ноябрендәге 2270 номерлы карар) шундый ук хокукый җайга салуны билгели торган акт буларак карауны сорый.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, мөрәҗәгать итүче түбәндәге норматив хокукый актларның конституциячеллегенә дәгъва белдерә:

– шәһәр Уставының 35 статьясындагы 1 өлешенең 36 пункты,

73 статьясындагы 3 һәм 9 өлешләре;

– район Уставының 54 статьясындагы 1 өлешенең 4 һәм 5 пунктлары, 11 пунктының унҗиденче абзацы, 83 статьясындагы 3 һәм 9 өлешләре;

– Тәртипнең 5.2 пункты, шикаять биргән вакытта гамәлдә булган редакциясендә;

– 2019 елның 24 декабрендәге 2844 номерлы карар һәм 2020 елның 26 ноябрендәге 2270 номерлы карар.

Шәһәр Уставының 35 статьясындагы 1 өлешенең 36 пункты федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән җирлекләрнең вәкиллекле органнары карамагына кертелгән башка вәкаләтләр, шулай ук шәһәр Уставы белән шәһәр җирлеге Советы компетенциясенә кертелгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы (алга таба шулай ук – шәһәр Советы) компетенциясен билгели.

Шәһәр Уставының 73 статьясындагы 3 өлеше нигезендә җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә; аларны рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен җирле үзидарә органнары шулай ук челтәр басмасыннан файдаланырга хокуклы; рәсми челтәр басмасында муниципаль хокукый актның тулы тексты басылып чыккан (урнаштырылган) очракта, матбугат басмасында аның күләмле график һәм таблица рәвешендәге кушымталары китерелмәскә мөмкин.

Шәһәр Уставының 73 статьясындагы 9 өлеше, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен дә кертеп, муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) тиешле булган массакүләм мәгълүмат чаралары чыганакларын ачыклый (1 һәм 2 пунктлар), шулай ук муниципаль хокукый актны яисә җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми бастырып чыгару дип аның тулы текстын беренче бастырып чыгару санала, дип билгели (7 абзац).

Район Уставының 54 статьясындагы 1 өлешенең 4 һәм 5 пунктлары төзелеш, транспорт һәм элемтә өлкәсендә, шулай ук халыкка торак-коммуналь, көнкүреш, сәүдә һәм башка хезмәт күрсәтү өлкәсендә шәһәр җирлеге җирле үзидарә башкарма-боеру органы вәкаләтләрен үтәү буенча Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба шулай ук – район Башкарма комитеты) компетенциясен билгели. Район Уставының 54 статьясындагы 1 өлешенең 11 пунктындагы унҗиденче абзацы белән район Башкарма комитеты компетенциясенә федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында каралган шәһәр җирлеге җирле үзидарә башкарма-боеру органының башка вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кертелгән.

Район Уставының 83 статьясындагы 3 һәм 9 өлешләрендә шәһәр Уставының 73 статьясындагы 3 һәм 9 өлешләренә охшаш нигезләмәләр бар, аларда, шул исәптән, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен дә кертеп, муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) массакүләм мәгълүмат чаралары төрләре китерелә.

Тәртипнең 5.2 пункты нигезендә (шикаять биргән вакытта гамәлдә булган редакциясендә) Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне тапшыру турында килешү Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары өчен яклар тарафыннан имзаланган көннән алып үз көченә керә һәм мәҗбүри була.

2019 елның 24 декабрендәге 2844 номерлы һәм 2020 елның 26 ноябрендәге 2270 номерлы карарлар белән Зеленодольск шәһәре торак фондының торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләмнәре билгеләнгән.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданин А.В. Туганов Зеленодольск шәһәрендә күпфатирлы йортта яши, анда 2020 елда, 2019 елның 24 декабрендәге 2844 номерлы карар нигезендә, торак урынны карап тоту өчен түләү күләме арттырылган һәм аена гомуми мәйданның 1 кв. метры өчен 17,36 сум тәшкил иткән. Аның фикеренчә, мондый түләү күләмен билгеләү район Башкарма комитеты компетенциясенә керми, чөнки шәһәр Уставының 7 статьясындагы 1 өлешенең 7 пункты нигезендә әлеге вәкаләт шәһәр җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә карый. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 131-ФЗ номерлы Федераль закон) 44 статьясындагы 1 өлешенең 5 пунктына таянып, мөрәҗәгать итүче мондый күләмне билгеләү кемнең компетенциясендә булуы турындагы мәсьәлә муниципаль берәмлек уставында хәл ителергә тиеш, шуңа бәйле рәвештә бу вәкаләт йә шәһәр Уставында Зеленодольск шәһәре Советына, йә район Уставында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына беркетелергә тиеш, дип саный. Әмма аталган норматив хокукый актларда әлеге вәкаләтләргә турыдан-туры күрсәтмәләр юк.

Шулай итеп, гражданин А.В. Туганов район Уставының 54 статьясындагы 1 өлешенең 4 һәм 5 пунктлары, 11 пунктының унҗиденче абзацы, шәһәр Уставының 35 статьясындагы 1 өлешенең 36 пункты нигезләмәләрендә җирле үзидарәнең кайсы органы – Зеленодольск шәһәре Советы яки район Башкарма комитеты – вәкаләтләренә Зеленодольск шәһәре торак фондының торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү вәкаләте керүе мәсьәләсендә хокукый билгесезлек бар, шуның белән хокукый дәүләтнең хакимиятләрне бүлү, тигезлек һәм гаделлек, гражданнарның дәүләт гамәлләренә ышанычын саклау конституциячел принциплары бозыла дип саный.

Димәк, китерелгән дәлилләр нигезендә мөрәҗәгать итүче 2019 елның 24 декабрендәге 2844 номерлы карар җирле үзидарәнең вәкиллекле һәм башкарма-боеру органнары арасында вәкаләтләрне бүлешү тәртибен бозып кабул ителгән дип саный. Моннан тыш, аның фикеренчә, аталган карар Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарының тиешле вәкаләтләре булмаган вакытта имзаланган, шуңа бәйле рәвештә ул карала торган хокукый актны шулай ук аны имзалау тәртибе буенча да конституциячел түгел дип тануны сорый.

Шундый ук нигезләр буенча гражданин А.В. Туганов җирле үзидарәнең вәкиллекле һәм башкарма-боеру органнары арасында вәкаләтләрне бүлешү тәртибен бозу өлешендә 2020 елның 26 ноябрендәге 2270 номерлы карарның конституциячеллегенә дәгъва белдерә.

Мөрәҗәгать итүче үзе шикаять биргән вакытта гамәлдә булган редакциясендә Тәртипнең 5.2 пункты җирле үзидарәне оештыру нигезләрен җайга салучы федераль закон нормаларына туры килми дип саный, чөнки Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне тапшыру турында килешүнең үз көченә керү вакытын ул, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 47 статьясындагы 2 өлешендә каралганча, рәсми басылып чыгу (халыкка игълан ителү) белән түгел, ә яклар тарафыннан имзалау факты белән бәйли.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин А.В. Туганов Татарстан Республикасы Конституция судыннан Зеленодольск шәһәре Советының 2021 елның 24 мартындагы 37 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 35 статьясындагы 1 өлешенең 36 пункты, 73 статьясындагы 3 һәм 9 өлешләре, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 24 мартындагы 61 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 54 статьясындагы 1 өлешенең 4 һәм 5 пунктлары, 11 пунктының унҗиденче абзацы, 83 статьясының 3 һәм 9 өлешләре, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2015 елның 27 мартындагы 514 номерлы (шикаять биргән вакытта гамәлдә булган редакциясендә) карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне тапшыру турында килешүләр төзү тәртибенең 5.2 пункты нигезләмәләрен, «Зеленодольск шәһәренең торак фондының торак урыннарын карап тоткан өчен түләү күләме турында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24 декабрендәге 2844 номерлы карарын, шулай ук «Зеленодольск шәһәре торак фондының торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләме турында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 26 ноябрендәге 2270 номерлы карарын Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 10, 22, 24 (икенче өлеш), 27 (беренче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш) һәм 116 (беренче һәм икенче өлешләр) статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә, кеше, аның хокуклары һәм ирекләре – иң зур хәзинә; кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау – Татарстан Республикасының бурычы; Татарстан Республикасында җирле үзидарә таныла һәм гарантияләнә; җирле үзидарә үз вәкаләтләре чикләрендә мөстәкыйль; җирле үзидарә органнары дәүләт хакимияте органнары системасына керми; Россия Федерациясе гражданнары Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, халыкара хокукның гомумтанылган принциплары һәм нормалары нигезендә барлык хокукларга һәм ирекләргә ия һәм бертигез бурычлы; дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләре, оешмалар, учреждениеләр, вазыйфаи затлар һәм гражданнар Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын үтәргә тиеш; Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре халыкара хокукның гомумтанылган принциплары һәм нормалары буенча һәм Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә таныла һәм гарантияләнә; закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген чыгышына, социаль һәм мөлкәти хәленә, яшәү урынына һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; расачыл, милли һәм башка билгеләр буенча гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен чикләүнең теләсә кайсы рәвеше йә аларга өстенлекләр билгеләү тыела; җирле үзидарә, закон нигезендә һәм үзенә җаваплылык алып, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне халыкның мөстәкыйль хәл итүен, муниципаль милек биләүне, аннан файдалануны һәм аның белән эш итүне тәэмин итә; җирле үзидарә референдум, сайлаулар, турыдан-туры ихтыяр белдерүнең башка рәвешләре аша, җирле үзидарәнең сайланулы һәм башка органнары, җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары аша гражданнар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.2. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 101 статьясында әгәр закон яисә башка норматив хокукый акт гражданнарның конституциячел хокукларына һәм ирекләренә кагылса һәм әгәр закон яисә башка норматив хокукый акт, аны карау судта яисә башка органда төгәлләнгән яки башланган конкрет эштә кулланылса яки кулланылырга тиеш булса, Татарстан Республикасы законы яисә башка норматив хокукый акт белән конституциячел хокуклар һәм ирекләрнең бозылуына шикаять бирү мөмкин була дип билгеләнгән.

Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан әлеге эш буенча шикаятьне карау барышында шәһәр Уставының 73 статьясындагы 3 һәм 9 өлешләренең, район Уставының 83 статьясындагы 3 һәм 9 өлешләренең, шулай ук Тәртипнең 5.2 пунктының (шикаять биргән вакытта гамәлдә булган редакциясендә) хокукый нигезләмәләре мөрәҗәгать итүченең конкрет эшен хәл иткәндә кулланылган яисә кулланылырга тиеш булуы расланмады. Муниципаль хокукый актларны һәм килешүләрне бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм үз көченә керү тәртибен ачыклаучы уставларның китерелгән нормаларын, шулай ук килешүләрнең үз көченә керү тәртибен билгеләүче Тәртипнең 5.2 пункты (шикаять биргән вакытта гамәлдә булган редакциясендә) нигезләмәләрен конституциячел түгел дип санап, мөрәҗәгать итүче асылда Татарстан Республикасы Конституция судыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба шулай ук – шәһәр Башкарма комитеты) һәм район Башкарма комитеты арасында төзелгән 2014 елның 1 мартындагы Вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүнең (алга таба шулай ук – Килешү) конституциячеллегенә, рәсми бастырып чыгару тәртибен саклау һәм үз көченә керү вакытын үтәү күзлегеннән чыгып, бәя бирүне сорый.

Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәгеләрне билгеләп үтәргә кирәк дип саный. Әлеге Килешү 2014 елның 1 мартында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында Зеленодольск шәһәре Советының 2014 елның 21 февралендәге 227 номерлы карарын һәм Зеленодольск муниципаль районы Советының күрсәтелгән вәкаләтләрне кабул итү турында 2014 елның 21 февралендәге 365 номерлы карарын үтәү йөзеннән төзелгән. Зеленодольск шәһәре Советының 2015 елның 28 сентябрендәге 8 номерлы карары белән шәһәр Башкарма комитеты бетерелгән. Димәк, Килешүнең гамәлдә булуы Зеленодольск шәһәре Башкарма комитетын бетерү факты белән туктатылган. Шулай итеп, 2014 елның 1 мартындагы Вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешү фактта 2015 елда юридик көчен югалткан.

Мөрәҗәгать итүче, күрсәтелгән Килешү үзе Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать иткән вакытта юридик көчкә ия иде дип санап, шулай ук аның район Башкарма комитетына әлеге Килешү текстын бирү турындагы таләп белән үзе мөрәҗәгать иткәннән соң басылуын исәпкә алып, шәһәр Уставы, район Уставы һәм Тәртип нормаларының конституциячеллеген, аларның эчтәлегеннән чыгып, җирле үзидарә органнары кабул иткән килешүләрне рәсми чыганакларда бастырып чыгармаска мөмкин булган актлар буларак, шик астына куйган.

Шул ук вакытта, Килешүнең фактта 2015 елда үз көчен югалтуын исәпкә алып, уставларның гамәлдәге нормаларында беркетелгән рәсми бастырып чыгару турында таләпләре аның үз көченә кергәндә кулланыла алмый, димәк, шикаятьтә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләләрне хәл иткәндә кулланыла алмый һәм аның конституциячел хокукларына һәм ирекләренә кагылмый. Тәртипнең дәгъва белдерелә торган 5.2 пунктын мөрәҗәгать итүче эшендә куллану мәсьәләсенә килгәндә, түбәндәгеләрне билгеләп үтәргә кирәк: Килешү төзегән вакытта җирле үзидарә органнары тарафыннан төзелә торган килешүләрнең яклар тарафыннан имзаланган көннән алып үз көченә керүен ачыклаучы Тәртиптә каралган җайга салу 131-ФЗ номерлы Федераль закон нормалары белән килештерелгән, анда Килешү төзегән вакытта мондый килешүләрне рәсми бастырып чыгару турында таләпләр булмаган, димәк гражданин А.В. Тугановның хокукларын бозуга китермәгән.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 63 статьясы нигезләмәләре белән үзара бәйләнештә 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, утырыш барышында мөрәҗәгатьне карауга алудан баш тартуга нигезләр ачыкланса, шуларның берсе – аның мөмкин булу критерийларына туры килмәве ачыкланган очракларда, эш алып баруны туктата.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, әлеге эш буенча шәһәр Уставының 73 статьясындагы 3 һәм 9 өлешләренең, район Уставының 83 статьясындагы 3 һәм 9 өлешләренең, Тәртипнең 5.2 пунктының (шикаять биргән вакытта гамәлдә булган редакциясендә) конституциячеллеген тикшерү өлешендә эш туктатылырга тиеш, чөнки мөрәҗәгать итүченең бу өлештә мөрәҗәгате мөмкин түгел.

1.3. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану практикасындагы мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, түбәндәгеләр әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып тора:

– Зеленодольск шәһәре Советының 2021 елның 24 мартындагы 37 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 35 статьясындагы 1 өлешенең 36 пункты һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск

муниципаль районы Советының 2021 елның 24 мартындагы 61 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 54 статьясындагы 1 өлешенең 4 һәм 5 пунктлары, 11 пунктындагы унҗиденче абзацының үзара бәйле нигезләмәләре, алар тарафыннан билгеләнгән җайга салу кысаларында Зеленодольск шәһәре торак фондының торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләмен билгеләүгә вәкаләтле җирле үзидарә органын ачыклау мөмкин булмаган дәрәҗәдә;

– «Зеленодольск шәһәренең торак фондының торак урыннарын карап тоткан өчен түләү күләме турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24 декабрендәге 2844 номерлы карары Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Зеленодольск шәһәре торак фондының торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү буенча хокуклылыгы өлешендә, шулай ук аны имзалау тәртибе буенча;

– «Зеленодольск шәһәре торак фондының торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләме турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 26 ноябрендәге 2270 номерлы карары Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Зеленодольск шәһәре торак фондының торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү буенча хокуклылыгы өлешендә.

2. Гражданин А.В. Туганов тарафыннан шикаять белдерелә торган нигезләмәләр җирле үзидарәне оештыру өлкәсенә кагыла, ул Россия Федерациясе Конституциясе нигезендә Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләргә карый (72 статьяның 1 өлешендәге «н» пункты).

Россия Федерациясе Конституциясенең әлеге нигезләмәләре Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми хокукый, территориаль, оештыру һәм икътисади принципларын һәм аны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен билгеләгән 131-ФЗ номерлы Федераль законда, шулай ук «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында (алга таба – 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) үз үсешен алган.

131-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясы нигезендә җирле үзидарә Россия Федерациясенең конституциячел төзелеше нигезләренең берсен тәшкил итә, Россия Федерациясенең бөтен территориясендә таныла, гарантияләнә һәм гамәлгә ашырыла. Россия Федерациясендә җирле үзидарә – халыкның Россия Федерациясе Конституциясендә, федераль законнарда, ә федераль законнарда каралган очракларда – Россия Федерациясе субъектлары законнарында билгеләнгән чикләрдә тәэмин ителүче үз хакимиятен, халык мәнфәгатьләреннән чыгып, тарихи һәм башка җирле традицияләрне исәпкә алып, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне турыдан-туры халык һәм (яисә) җирле үзидарә органнары аша мөстәкыйль рәвештә һәм җаваплылыкны үз өстенә алып гамәлгә ашыру рәвеше.

Муниципаль берәмлекләр халкы тарафыннан турыдан-туры һәм (яисә) җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый актлар кабул ителә, алар Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, 131-ФЗ номерлы Федераль законга, башка федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актларына, шулай ук Россия Федерациясе субъектлары конституцияләренә (уставларына), законнарына, башка норматив-хокукый актларына каршы килмәскә тиеш (131-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 һәм 4 өлешләр).

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү максатларында җирле үзидарә органнары муниципаль берәмлек уставын кабул итү, аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча вәкаләтләргә ия (131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 1 пункты). Югарыда аталган Федераль законның 43 статьясындагы 1 өлешенең 1 пункты, 44 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты һәм 3 өлешенең нигезләмәләре буенча муниципаль берәмлек уставы муниципаль хокукый актлар системасына керә, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан кабул ителә һәм муниципаль хокукый актларның төрләрен, кабул итү (бастырып чыгару), рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм үз көченә керү тәртибен билгели. Эчтәлеге буенча охшаш нормалар 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 өлешендәге 6 пунктында һәм 7 статьясындагы 3 өлешендә беркетелгән.

Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан җирле әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый актлар кабул ителә, алар системасына, шул исәптән, җирле администрациянең һәм башка җирле үзидарә органнарының һәм җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларының муниципаль берәмлек уставында каралган хокукый актлары керә (131-ФЗ номерлы Федераль законның 7 һәм 43 статьялары).

Шулай итеп, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актларны кабул итеп, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнары федераль һәм республика законнары нигезендә үзләренә бирелгән вәкаләтләр кысаларында эш иткән.

3. Татарстан Республикасы Конституциясенең 10, 116 (беренче өлеш) һәм 118 (беренче өлеш) статьяларының үзара бәйле нигезләмәләре буенча Татарстан Республикасында җирле үзидарә таныла һәм гарантияләнә, ул үз вәкаләтләре чикләрендә мөстәкыйль һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне халыкның мөстәкыйль хәл итүен тәэмин итә. Шундый ук нигезләмәләр Россия Федерациясе Конституциясенең 12, 130 (1 өлеш) һәм 132 статьяларында беркетелгән.

Күрсәтелгән хокукый җайга салуга 1985 елның 15 октябрендәге Европа җирле үзидарә хартиясе (Россия Федерациясе тарафыннан 1998 елның 11 апрелендә ратификацияләнгән) нигезләмәсе тәңгәл килә, аның нигезендә җирле үзидарә органнары үзләренең вәкаләтләре өлкәсендәге һәм нинди дә булса башка хакимият органы карамагында булмаган теләсә нинди мәсьәлә буенча үз инициативасын гамәлгә ашыру өчен законда билгеләнгән чикләрдә тулысынча ирекле эш итәләр (4 статьяның 2 пункты).

3.1. Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясындагы 3 өлеше буенча җирле үзидарә органнарына социаль яллау шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондыннан торак урыннар яллау шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен торак урыннан файдаланган өчен түләү (яллау өчен түләү), торак урынны тоткан һәм аңа ремонт ясаган өчен түләү күләме һәм күпфатирлы йортка идарә итү ысулын сайлап алу турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны тоткан һәм аңа ремонт ясаган өчен түләү күләмен билгеләү буенча вәкаләт бирелгән. Күрсәтелгән кодексның 158 статьясындагы 4 өлешендә шулай ук, әгәр күпфатирлы йорттагы торак урыннар милекчеләре үзләренең гомуми җыелышында торак урын тоткан һәм аңа ремонт ясаган өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән булсалар, мондый күләм җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә, дип каралган.

Шуның белән бергә гамәлдәге законнар әлеге вәкаләт җирле үзидарәнең кайсы органы — муниципаль берәмлекнең вәкиллекле яисә җирле администрация (муниципаль берәмлекнең башкарма-боеру органы) компетенциясенә керүен ачыклаучы нигезләмәләрне беркетми.

131-ФЗ номерлы Федераль законның 34 статьясындагы 1 һәм 3 өлешләренең үзара бәйле нигезләмәләре буенча, вәкаләтләр, аерым алганда муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы һәм җирле хакимият (муниципаль берәмлек башкарма-боеру органы) вәкаләтләре муниципаль берәмлек уставында билгеләнергә тиеш. Карала торган эштә бу Зеленодольск шәһәре торак фондының торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү кем компетенциясендә булу мәсьәләсе муниципаль берәмлек уставында хәл ителергә тиеш дигәнне аңлата.

Шәһәр Уставы белән Зеленодольск шәһәре торак фондының торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү мәсьәләсе шәһәр җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелгән (7 статьяның 1 өлешендәге 7 пункты). Шәһәр Уставының 30 статьясы нигезендә шәһәр Советы – шәһәр җирлеге җирле үзидарәсенең вәкиллекле органы. 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясындагы 10 өлешендә муниципаль берәмлек вәкиллекле органының махсус компетенциясенә кергән мәсьәләләр билгеләнгән. Шул ук вакытта әлеге статьяның 11 өлеше нигезендә муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнарының башка вәкаләтләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителә торган Россия Федерациясе субъектлары конституцияләре (уставлары), законнары, муниципаль берәмлекләр уставлары белән билгеләнә. Шундый ук нигезләмәләр 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22 статьясындагы 8 һәм 9 өлешләрендә дә бар.

Шулай итеп, шәһәр Уставының 35 статьясында шәһәр Советы вәкаләтләре исемлеге беркетелгән, ул ачык, чөнки күрсәтелгән статьяның 1 өлешендәге дәгъва белдерелә торган 36 пунктында федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән җирлекләрнең вәкиллекле органнары карамагына кертелгән башка вәкаләтләре, шулай ук шәһәр Уставы белән шәһәр Советы компетенциясенә кертелгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мөмкинлеге билгеләнгән.

131-ФЗ номерлы Федераль законның, 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының китерелгән нигезләмәләрен, шәһәр Уставының карала торган нормасының сүзгә-сүз эчтәлеген анализлау торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү вәкаләтләре, шәһәр Уставы белән шәһәр Советы карамагына кертелмәгән кебек үк, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карамагына кертелмәгән булуын күрсәтә.

131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы нигезендә җирле хакимияткә (муниципаль берәмлекнең башкарма-боеру органына) муниципаль берәмлек уставы белән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләр һәм җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектлары законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен вәкаләтләр бирелә.

Шәһәр Уставының 52 статьясында федераль законнар нигезендә шәһәр җирлеге башкарма-боеру органы вәкаләтләрен үтәү район Башкарма комитетына йөкләнүе күздә тотыла.

Район Уставының гражданин А.В. Туганов шикаять белдерелә торган 54 статьясындагы 1 өлешенең 4 һәм 5 пунктлары төзелеш, транспорт һәм элемтә өлкәсендә, шулай ук халыкка торак-коммуналь, көнкүреш, сәүдә һәм башка хезмәт күрсәтү өлкәсендә шәһәр җирлеге җирле үзидарә башкарма-боеру органы вәкаләтләрен үтәү буенча район Башкарма комитеты вәкаләтләрен билгели. Шул ук вакытта шикаять белдерелә торган статьяның 1 өлешендәге 11 пунктының унҗиденче абзацында район Башкарма комитеты федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында каралган шәһәр җирлеге җирле үзидарә башкарма-боеру органының бүтән вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга хокуклы дип билгеләнгән.

Шәһәр Уставының шәһәр Советы вәкаләтләрен регламентлаштыручы 35 статьясы нормалары, шул исәптән әлеге статьяның 1 өлешендәге 36 пункты нигезләмәләре һәм район Уставының район Башкарма комитеты компетенциясен билгеләүче 54 статьясындагы 1 өлешенең 4 һәм 5 пунктлары, 11 пунктының унҗиденче абзацы нигезләмәләре эчтәлегенә системалы анализ күрсәткәнчә, Зеленодольск шәһәре торак фондының торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү вәкаләтләре турыдан-туры җирле үзидарәнең вәкиллекле органына да, башкарма-боеру органына да беркетелмәгән. Шул ук вакытта шәһәр Уставының 35 статьясындагы 1 өлешенең 36 пункты һәм район Уставының 54 статьясындагы 1 өлешенең 11 пунктының унҗиденче абзацы белән шәһәр Советы да, район Башкарма комитеты да, уставларда конкретлаштырылганнардан тыш, башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра ала дип каралган. Моннан әлеге нормаларның конкурентлык характеры булуы күренә, чөнки устав нормаларында кулланыла торган бланкет (сылтау) конструкциясе торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү вәкаләтен җирле үзидарәнең вәкиллекле органына да, башкарма-боеру органына да кертергә мөмкинлек бирә. Җирле үзидарәнең вәкиллекле һәм башкарма-боеру органнары вәкаләтләрен билгели торган уставлар нигезләмәләренең эчтәлегендәге билгесезлек район Башкарма комитеты тарафыннан кабул ителгән шикаять белдерелә торган 2019 елның 24 декабрендәге 2844 номерлы һәм 2020 елның 26 ноябрендәге 2270 номерлы карарларның законлы булуын шик астына куя, чөнки район Башкарма комитеты Зеленодольск шәһәре территориясендә район Уставы белән тиешле җайга салуны кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органы буларак карала алмый.

Моннан тыш, дәгъва белдерелә торган хокукый җайга салуда Зеленодольск шәһәре торак фондының торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләмен билгеләргә вәкаләтле органны ачыкларга мөмкинлек бирә торган нормаларның булмавы, әлеге эшне карау кысаларында суд утырышында катнашучылар тарафыннан тәкъдим ителгән позицияләр белән танышу күрсәткәнчә, шикаять белдерелә торган нормаларны, шул исәптән тиешле норматив актларны кабул итү буенча вәкаләтләр бирелгән җирле үзидарә органнары тарафыннан да төрлечә аңлауга китерә. Шуңа бәйле рәвештә дәгъва белдерелә торган норматив-хокукый актларны чыгарган җирле үзидарә органнары вәкилләренең баштан ук Зеленодольск шәһәре торак фондының торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләмен шәһәр Башкарма комитеты билгеләве турындагы дәлилләре белән дә килешергә ярамый, ул 2014 елның 1 мартындагы Килешү кысаларында үз вәкаләтләренең бер өлешен, шул исәптән Зеленодольск шәһәре торак фондының торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү буенча да, район Башкарма комитетына тапшырган. Әмма әлеге Килешүне шәһәр Башкарма комитетының төзелеш, транспорт һәм элемтә өлкәсендә, шулай ук халыкка торак-коммуналь, көнкүреш, сәүдә һәм башка хезмәт күрсәтү өлкәсендә вәкаләтләрен билгели торган шәһәр Уставының (Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре Советының 2014 елның 19 сентябрендәге 269 номерлы карары редакциясендә) 48 статьясы нигезләмәләре белән үзара бәйләнештә анализлау күрсәткәнчә, торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү вәкаләте шәһәр Башкарма комитетына беркетелмәгән һәм, димәк, район Башкарма комитетына да тапшырыла алмаган.

Шулай итеп, район Башкарма комитеты тарафыннан, уставларның югарыда китерелгән нормаларының һәм хокук куллану практикасының сүзгә-сүз эчтәлегеннән чыгып, Зеленодольск шәһәре торак фондының торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турыдан-туры килеп чыга торган нормаларга беркетелгән вәкаләтләргә түгел, ә әлеге районда гомум кабул ителгән һәм гамәлдә булган кагыйдәгә нигезләнә, аның нигезендә әлеге вәкаләтләрне шәһәр Башкарма комитеты гамәлгә ашырган, ә аны бетерү турында Зеленодольск шәһәре Советы тарафыннан 2015 елның 28 сентябрендәге 8 номерлы карар кабул ителгәннән соң, шәһәр Уставының (Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре Советының 2015 елның 16 мартындагы 311 номерлы карары редакциясендә) 46 статьясындагы 1 өлеше нигезендә күрсәтелгән вәкаләтләр район Башкарма комитетына күчкән. Мондый тәҗрибә җирле үзидарә органнары тарафыннан, шул исәптән җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары тарафыннан да, законлылык принцибына туры килмәвенә һәм процессуаль бозуларга юл куелуга карамастан, беркайчан да шик астына куелмаган.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, шәһәр Уставының һәм район Уставының дәгъва белдерелә торган хокукый нигезләмәләре үзләре дә, шулай ук Зеленодольск шәһәре территориясендә гамәлдә булган хокукый җайга салу системасында да Зеленодольск шәһәре торак фондының торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләмен билгеләүгә вәкаләтле җирле үзидарә органын төгәл, ачык һәм ике төрле аңлашылмый торган итеп ачыкларга мөмкинлек бирми, димәк, район Башкарма комитеты тарафыннан мондый түләү күләмен билгели торган актларны кабул итү өчен хокукый нигез була алмый.

Россия Федерациясе Конституция Суды берничә тапкыр билгеләп үткәнчә, Россия Федерациясе Конституциясендә, аның 1 (1 өлеш), 4 (2 өлеш), 15 (1 һәм 2 өлешләр) һәм 19 (1 һәм 2 өлешләр) статьяларында беркетелгәннәрдән килеп чыга торган хокукый норманың билгелелеге, ачыклыгы һәм ике төрле аңлашылмаучанлыгы гомумхокукый критериен, хокукый дәүләт, закон өстенлеге һәм юридик тигезлек принципларын үтәмичә, аны бертөсле аңлау һәм, димәк, куллану мөмкин түгел; хокукый җайга салуның бер мәгънәле булмавы, ачык булмавы һәм каршылыклылыгы аның эчтәлеген тәңгәл аңлатуга каршы килә, хокук куллану процессында чикләнмәгән карау мөмкинлеген бирә, башбаштаклыкка китерә һәм шуның белән конституциячел хокукларны һәм ирекләрне яклау гарантияләрен какшата; шуңа күрә хокукый норманың билгелелеге таләбен бозу үзеннән-үзе мондый норманы Россия Федерациясе Конституциясенә каршы килә дип тану өчен тулысынча җитәрлек булырга мөмкин (2011 елның 20 декабрендәге 29-П номерлы, 2015 елның 2 июнендәге 12-П номерлы, 2017 елның 19 июлендәге 22-П номерлы, 2018 елның 16 мартындагы 11-П номерлы һ.б. карарлар).

Шулай да Татарстан Республикасы Конституция суды әлеге эшне караганда ачыкланган бозу фактларын формаль билгеләү белән генә чикләнергә ярамый дип саный, чөнки суд үзенә йөкләнгән вәкаләтләрне башкарганда бер яктан кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашырганда башка затларның хокукларын һәм ирекләрен бозу рөхсәт ителмәвен дә кертеп, конституциячел мөһим мәнфәгатьләр балансын һәм икенче яктан – катнашучылары мәнфәгатьләрендә хокукый мөнәсәбәтләрнең тотрыклылыгын тәэмин итү кирәклеген игътибарга алырга тиеш.

Татарстан Республикасы Конституция суды әлеге эштә шәһәр Уставының 35 статьясындагы 1 өлешенең 36 пунктының һәм район Уставының 54 статьясындагы 1 өлешенең 4 һәм 5 пунктларының, 11 пунктының унҗиденче абзацының үзара бәйле нигезләмәләрен, алар тарафыннан билгеләнгән җайга салу кысаларында торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләмен билгеләүгә вәкаләтле җирле үзидарә органын ачыклау мөмкин булмаган дәрәҗәдә, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип тану әлеге эштә район Башкарма комитетының дәгъва белдерелә торган карарларын, аның тарафыннан элегрәк кабул ителгән башка шундый муниципаль хокукый актлар кебек үк, котылгысыз рәвештә конституциячел түгел дип тану зарурлыгына китерәчәк, бу хокукый җайга салуда җитешсезлек тудырачак, ул әлеге очракта Татарстан Республикасы Конституциясен турыдан-туры кулланып бетерелә алмый һәм Зеленодольск шәһәре территориясендә гамәлдә булган муниципаль норматив хокукый актларга системалы үзгәрешләр кертүне таләп итә дип саный. Шул ук вакытта түбәндәгеләрне дә билгеләп үтәргә кирәк: торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү буенча норматив хокукый актларны кабул итү Россия Федерациясе Торак кодексының 156 һәм 158 статьялары белән җирле үзидарә органнары компетенциясенә кертелгән, шуннан чыгып, милекчеләр мондый түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән очракта, мондый җайга салуны билгеләү – җирле үзидарә органнарының бурычы. Шуның белән, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актларны хокук өлкәсеннән төшереп калдыру торак фондыннан файдалану һәм сакланышын тәэмин итү буенча тиешле контроль булмауга, шулай ук гражданнарның аларга караган торак урыннарында яшәү өчен имин һәм уңайлы шартлар булдыру белән бәйле җитди тискәре нәтиҗәләргә китерергә мөмкин.

Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция суды, акыллы тотнаклылык принцибына таянып, объектив килеп туган чынбарлыкны исәпкә алып, әлеге эштә шәһәр Уставының 35 статьясындагы 1 өлешенең 36 пунктының һәм югарыда аталган аспектта район Уставының 54 статьясындагы 1 өлешенең 4 һәм 5 пунктларының, 11 пунктының унҗиденче абзацының үзара бәйле нигезләмәләрен, шулай ук шикаять белдерелә торган 2019 елның 24 декабрендәге 2844 номерлы һәм 2020 елның 26 ноябрендәге 2270 номерлы карарларын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танудан тыелып калырга мөмкин, дип саный. Шул ук вакытта җирле үзидарәнең вәкиллекле органнарыннан – Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып һәм әлеге Карарны исәпкә алып – Зеленодольск шәһәре торак фондының торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләмен билгеләргә вәкаләтле органны ачыклау һәм, мондый вәкаләт кемгә билгеләнүеннән чыгып, Зеленодольск шәһәре территориясендә гамәлдә булган хокукый җайга салуга тиешле үзгәрешләр кертү бурычы төшерелми.

3.2. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 83 статьясындагы беренче өлешенең 3 пункты һәм 103 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларның шул исәптән аларны имзалау тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәвен билгели.

131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясындагы 1 өлешенең икенче абзацы нигезендә җирле хакимияттә бер генә башлык идарә итү принципларында җирле хакимият башлыгы җитәкчелек итә. Шундый ук нигезләмәләр 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясында беркетелгән.

Вазыйфага контракт буенча билгеләнеп куела торган җирле администрация башлыгы – муниципаль берәмлек башкарма комитеты җитәкчесе, ул федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль берәмлек уставы, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән вәкаләтләре кысаларында җирле әһәмияттәге мәсьәләләр һәм федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен башкаруга бәйле мәсьәләләр буенча җирле администрация карарларын, шулай ук җирле администрация эшен оештыру мәсьәләләре буенча җирле администрация күрсәтмәләрен чыгара (45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясындагы 1 өлешенең икенче абзацы, 8 өлеше).

Район Уставының 51 статьясындагы 2 өлеше нигезендә район Башкарма комитеты структурасына Башкарма комитет җитәкчесе, аның урынбасарлары, район Башкарма комитетының тармак (функциональ) һәм (яки) башка органнары керә дип билгеләнгән.

Район Башкарма комитетын район Башкарма комитеты җитәкчесе җитәкли; аерым оештыру-боеру функцияләрен гамәлгә ашыру өчен район Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасарлары бар; район Башкарма комитеты җитәкчесе вакытлыча булмаганда (авыруга яки ялга бәйле рәвештә) яки ул үз вазыйфаларын башкара алмаганда яисә вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, аның вәкаләтләрен билгеләнгән вазыйфалар бүленеше буенча район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарларының берсе башкара (район Уставының 55 статьясындагы 1, 6 өлешләр).

Район Башкарма комитеты җитәкчесе законнар, район Уставы һәм Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы карарлары белән билгеләнгән район Башкарма комитеты вәкаләтләре чикләрендә, җирле әһәмияттәге мәсьәләләр һәм федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча район Башкарма комитеты карарларын, шулай ук район Башкарма комитеты эшен оештыру мәсьәләләре буенча район Башкарма комитеты боерыкларын чыгара (район Уставының 82 статьясы).

Шуның белән бергә Татарстан Республикасы Конституция суды, район Уставының күрсәтелгән нигезләмәләре билгеләнгән тәртиптә кирәкле хокуклылык бирелгән башка вазыйфаи затлар тарафыннан тиешле актларны имзалауның теләсә нинди башка хокукый мөмкинлеген юкка чыгаручы буларак бәяләнә алмый, чөнки башкача булу, район Башкарма комитеты җитәкчесе булмаганда, аның үз эшчәнлеген башкару мөмкин булмавына китерер иде, дип билгели. Моннан тыш, район Уставының 58 статьясындагы 8 пункты Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарларына аерым оештыру-боеру функцияләрен йөкләүнең хокукый мөмкинлеген күздә тота, аларга төрле хокукый актларны имзалауны да кертергә мөмкин. Әмма вәкаләтләрне әлеге тапшыру район Башкарма комитеты җитәкчесенең әлеге җирле үзидарә органы тарафыннан аның компетенциясенә керүче вәкаләтләрнең үтәлеше өчен персональ җаваплылыгын кире какмый, бу турыдан-туры район Уставының 58 статьясындагы 1 пунктында беркетелгән.

Шуның белән Татарстан Республикасы Конституция суды муниципаль хокукый актларны билгеләнгән тәртиптә кирәкле вәкаләтләр бирелгән район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары тарафыннан имзалау район Уставының 55 статьясындагы 1 һәм 6 өлешләрендә беркетелгән объектив сәбәпләр барлыкка килгәндә генә мөмкин, дип билгели. Район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарлары тарафыннан мондый хокукны гамәлгә ашыру, иң беренче чиратта, район Башкарма комитетының нәтиҗәле эше өчен шартлар тудыруга, тиешле карарлар вакытында кабул ителмәгән очракта, нәтиҗәләрне тиешле дәрәҗәдә кисәтүгә юнәлдерелергә тиеш. Шуның белән бергә, Татарстан Республикасы Конституция суды район Башкарма комитетының норматив хокукый актларын имзалау хокукын системалы рәвештә урынбасарларга тапшыру практикасы гражданнарның законга һәм гавами хакимият гамәлләренә ышаныч принцибын саклап калуга ярдәм итми һәм хокук куллануда чикләнмәгән каралуга һәм законсызлыкка китерергә мөмкин дип билгеләп үтә.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Конституция суды мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган 2019 елның 24 декабрендәге 2844 номерлы карар аны имзалау тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дигән нәтиҗә ясый.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6, 63 статьяларына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71, 73 статьяларына, 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

карар чыгарды:

1. «Зеленодольск шәһәренең торак фондының торак урыннарын карап тоткан өчен түләү күләме турында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24 декабрендәге 2844 номерлы карарын, аны имзалау тәртибе буенча, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. Әлеге эштә Татарстан Республикасы Конституция суды Зеленодольск шәһәре Советының 2021 елның 24 мартындагы 37 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 35 статьясындагы 1 өлешенең 36 пункты, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 24 мартындагы 61 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 54 статьясындагы 1 өлешенең 4 һәм 5 пунктлары, 11 пунктының унҗиденче абзацы нигезләмәләрен, алар тарафыннан билгеләнгән җайга салу кысаларында Зеленодольск шәһәре торак фондының торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләмен билгеләүгә вәкаләтле җирле үзидарә органын ачыклау мөмкин булмаган дәрәҗәдә, шулай ук «Зеленодольск шәһәренең торак фондының торак урыннарын карап тоткан өчен түләү күләме турында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24 декабрендәге 2844 номерлы карарын, «Зеленодольск шәһәре торак фондының торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләме турында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 26 ноябрендәге 2270 номерлы карарын Зеленодольск шәһәре торак фондының торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү буенча Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының хокуклылыгы өлешендә Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танудан тыелып кала.

Моның белән җирле үзидарәнең вәкиллекле органнарыннан – Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып һәм әлеге Карарны исәпкә алып – Зеленодольск шәһәре торак фондының торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләмен билгеләргә вәкаләтле органны ачыклау һәм, мондый вәкаләт кемгә билгеләнүеннән чыгып, Зеленодольск шәһәре территориясендә гамәлдә булган хокукый җайга салуга тиешле үзгәрешләр кертү бурычы төшерелми.

3. Зеленодольск шәһәре Советының 2021 елның 24 мартындагы 37 номерлы карары белән кабул ителгән Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 73 статьясындагы 3 һәм 9 өлешләре, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 24 мартындагы 61 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 83 статьясындагы 3 һәм 9 өлешләре, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2015 елның 27 мартындагы 514 номерлы (шикаять биргән вакытта гамәлдә булган редакциясендә) карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне тапшыру турында килешүләр төзү тәртибенең 5.2 пункты нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерүгә кагылышлы өлешендә әлеге эш буенча эш башкаруны туктатырга.

4. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

5. Әлеге Карар «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталарында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

101-П **Татарстан Республикасы Конституция суды**

УКУЧЫ СҮЗЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов

ТӘРӘЗӘЛӘР – ӘНКӘЙ КҮЗЛӘРЕ

Дөнья куып хәлем беткән чакта,
Авылыма кайтып тын алам.
Җаннарыма синдә илһам алып,
Әйтерсең лә туам яңадан.

Нигезләрне ялгыз калдырмагыз,
Югалтмагыз яшьлек эзләрен.
Тәрәзәләр сагыш белән карый,
Әйтерсең лә әнкәй күзләре.

Туган җирнең бардыр дәвалары,
Тән ярасы монда онытыла.
Нигеземне ташлап киткәнгәме,
Җан ярасы гына кузгала.

Үткәннәргә әгәр кайтып булса,
Китмәс идем мин дә читләргә.
Гомер үтә туган җирне сагнып,
Бәхет эзләп һаман чит җирдә.

Рөстәм ЗӘКУАН

Герман кызы

Казанда яшәүче хезмәт ветераны Назилә Хәйруллина татар матбугатын яратып укый, «Ватаным Татарстан» газетасының тугры укучысы. Гомер буе татар матбугатына язылып, мәктәп, китапханәләргә тарата. Шул рәвешле башкаларны да белемле булырга өнди. «Ватаным Татарстан» газетасының тупланмасын Чуашстанның Кармыш авылы мәдәният йортына, авыл китапханәсенә дә җибәрде.

Назилә апа Питрәч районы Шәле авылында туа. Бөек Ватан сугышыннан орден-медальләр белән кайткан баһадир Кыяметдин кызы була ул. Әтисе белән бик горурлана. Үзе дә аның йөзенә тап төшермәскә тырыша. Әтисенә ат җигәргә, кадак кагарга, утын кисәргә – кыскасы, барлык эшләрдә дә булышкан чая кызны «Герман кызы» дип йөртәләр. Назилә бик тә туган җанлы булып үсә. Беркайда да югалып калмый: Казанга китеп эшкә урнаша, тырышып, фидакарь хезмәт итә, гаилә кора.

Кызы Альбинаның гаиләсенә, оныкларына булышып яши. Әле күптән түгел генә оныклары белән Казансу елгасы буендагы китапханәгә барган, андагы матурлыкка шаккатып кайткан. Өен чип-чиста, тәртиптә тотып, концерт-театрларга да йөрергә өлгерә Назилә апа. Салават концертына бу юлы өч тапкыр рәттән барган. «Бик яратам җырлавын», – ди.

Назилә апа мәчеттә белем ала, бүген ул дин юлында. Һәр таңда илгә-көнгә тынычлык, һәр кешегә сәламәтлек, бәхет тели. Әрвахларны изге догадан калдырмый. Үзе дә кызы, оныклары кадерендә яши.

Равилә МӨБАРӘКШИНА.
Казан

Туган телгә – тәүге адым

Сургут шәһәрендәге Сургут районы Белый Яр бистәсендә «Акъяр» татар оешмасы күптән түгел генә барлыкка килде әле. Әмма ул бистә тормышына яңа төсмер өстәргә өлгерде дә инде. «Умка» өстәмә белем бирү үзәгендә «Акъяр» татар оешмасы каршында эшләүче якшәмбе татар мәктәбе дә үзенең ишекләрен ачты. Ачылу тантанасына халык күп җыелды.

Килгән кунакларны ачык йөз, тәмле сүз белән хуҗабикә Рәзилә Хәерова һәм оешманың активисты Гөлия Садретдинова каршы алды.

Ямь өстенә ямь өстәп, холлда һәвәскәр рәссам Ләйсән Кәримованың картиналарыннан күргәзмә дә оештырылган иде. Рәссам үзе дә чарада катнашып, уй-фикерләре, планнары турында сөйләде. Картиналардан гына түгел, Ләйсәннең үзеннән дә татар халкына хас мөлаемлык, тыйнаклык, самимилек бөркелеп тора.

Җылы әңгәмә чәй табыны янында дәвам итте.

Төп максат – татар мәктәбе ачу булганлыктан, Гүзәл Шәрәфетдинова күпьеллык тәҗрибәсе белән уртаклашты. Остазларының чыгышына җанлы мисал булып, аның шәкертләре дә килгән иде. Гүзәл Минсалиховнаның бу өлкәдә тәҗрибәсе зур, аның телне өйрәтү буенча үз методикасы да булдырылган. Шуңа күрә «Акъяр» оешмасы аны татар якшәмбе мәктәбен җитәкләргә чакырды. Гүзәл Минсалиховна бистәнең 3 нче мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укыта, күпләр өчен бик таныш шәхес.

Шулай итеп, «Акъяр» татар якшәмбе мәктәбе ике җирдә – Белый Ярда һәм Сургут шәһәренең үзәгендә эшләячәк. Дәресләрне бистәнең 3 нче мәктәбе укытучылары алып барачак.

Өлкәннәр оештыру эшләре турында сөйләшүне дәвам итте, ә балалар беренче дәрескә икенче бүлмәгә күчтеләр. Укытучылар беренче дәресне мәктәп темасына багышлап әзерләделәр. Балалар бер дәрес эчендә 10лап татарча сүз өйрәнделәр һәм «Өйрәтәләр мәктәпләрдә» җырының бер куплетын татарча җырларга да өлгерделәр. Дәрес ахырында өйрәнгән сүзләрдән җөмләләр төзеп һәм җыр башкарып, әти-әниләрен гаҗәпкә дә калдырдылар. Кайбер ата-аналарның хәтта күзләрендә сөенечтән яшь тамчылары җемелди иде.

Бик тә кирәкле эш башланды бу көнне. Озын гомерле булсын!

Гөлсинә МӨБАРӘКШИНА.
Сургут шәһәре

БАЯН БЕЛӘН КИЛЕГЕЗ!

Авылда үтә торган мәҗлесләрдә Гарифуллиннар гаиләсенә ял сирәк эләгә. Аларны ашка: «Баян белән килегез!» – дип чакыралар, бәйрәмнәрнең музыкаль өлешен күп вакыт аларга йөклиләр. Әмир баян уйный, Гөлия аңа кушылып җырлый.

Гарифуллиннар – гомумән, җырлы-моңлы халык. Әмирнең Әмин, Рифкать абыйлары, улы Илвир да – баянчылар, хатыны һәм башка кайбер туганнары – оста җырчылар. Тагын бер уллары Данияр, шулай ук Илвир төрле бәйрәмнәрдә алып баручылар буларак билгеле. Аларның берсе – Әлмәттә, икенчесе Түбән Камада урнашкан, төпчекләре Илсур Чирмешәндә аграр техникумда автомеханиклыкка укыган, авылда яши.

Әтиләре Зәки абый үзе уйнамаса да, малайларына гармун алып куя. Яңгыравыклы, матур тавышлы «Чайка»да Әмир, ике як төймәләргә дә басып, 3 нче сыйныфта укыганда ук көйләр чыгара башлый. Әле аннан соң да бер гармун, ике баян туздыра. Әмирнең хәзерге баяны 35 еллык, әмма яхшы сакланган, еш уйнап торгач, төймәләре майлаган кебек, ансат басылалар.

– Гармун, баян һава алмашканны яратмый. Кайвакыт башта өйдә, аннары тышкы якта уйныйсың. Элек бит гел шулай иде. Кышын да ишегалдына чыгып биеделәр. Каядыр барганда, баянны футлярына салып йөртсәң яхшы, – ди ул.

Аңа бүген дә баянын кулына алмый булмас, туган көне уңаеннан кичкә туган-тумачаларын көтәләр. Махсус чакыру белән түгел, үзләре белеп киләләр, бергә күңел ачалар. Иртәгә авыл мәдәният йортында аның хөрмәтенә тагын бер табын көйләргә әзерләнәләр. «Ак калфак» оешмасының Түбән Кәминкәдәге бүлекчәсендә шундый гадәт: бер-берсенең юбилейларында, туган көннәрендә мәҗлескә җыелалар.

– Бездә әле дә 4–5 баянчы бар. Элек Түбән Кәминкәдә алар дистәләп иде. Күбесе читкә китте, кайберләре вафат. Бер елны якташ гармунчыларны, баянчыларны чакырып, авылда зур чара оештырдык, дистәләп музыкант кайтты. Гармун яки баянда уйнарга иң элек теләк, тырышлык кирәк. Сәләтең, моңың да бар икән, шөгыльләнергә иренмә инде. Менә мин һәр кич диярлек кулыма баян алам, уйныйм да, җырлыйм да. Хатыным – шәфкать туташы булып эшләүче Гөлия гел янда. Бергә телевизордан музыкаль тапшырулар карыйбыз, яңа җырлар ишеткәч, отып калырга тырышабыз. Бер-ике тапкыр тыңласам, мин көйне истә калдырам, ә

Гөлиянең хәтере яхшырак, җыр сүзләрен ул язып куя, – ди Әмир.

«Ялгыз аккош» дигән җырның көен исә ул үзе, ә сүзләрен хатыны Гөлия язган икән. Тиздән репертуарларына тагын берсе өстәлергә тора. Дөрес, ул әле халыкка таныш түгел. «Түбән Кәминкә» җыры. Анысын да үзләре иҗат иткән.

Иң яраткан җырчылары турында да кызыксынам.

– Алар күп, аеруча Салават Фәтхетдинов, Габделфәт Сафин ошый, бик моңлы, үзенчәлекле җырчылар. Билгеле, улларыбыз җырлаганда да рәхәт безгә, ниндидер горурлык хисе уяна, – ди Әмир.

Җырлап, баянда уйнап кына яши Әмир Гарифуллин диясе килми, ул физик хезмәттә дә алдынгы. 40 елга якын комбайнда эшләгән, әле бер елны «Нива»да эшләүчеләр арасында районда беренче булып, Казанда узган «Уңыш бәйрәме»нә барган, бүләкләр алган. Соңгы бер елда җирлектәге көпчәкле трактор белән Түбән Кәминкә һәм Кара Чишмә авылларындагы урам юлларын кардан чистарта, үләннәрне чаба. Кар күп булганда, еш кына иртәнге сәгать дүрттә үк тракторын кабыза.

Гарифуллиннар ел саен 7–8 баш эре мал симертәләр. Иткә үзләренең клиентлары бар.

Кадыйр ГОМӘРОВ.
Чирмешән районы Түбән Кәминкә авылы

АЭСК

«ООО «Альтернативная энергосбытовая компания» уведомляет, что в соответствии с постановлением Правительства Российской Федерации № 24 от 21.01.2004 «Об утверждении стандартов раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии» на официальном сайте Компании http://tataesk.ru/ размещена в полном объеме информация об объеме фактического полезного отпуска электроэнергии и мощности по тарифным группам в разрезе территориальных сетевых организаций по уровням напряжения ООО «Альтернативная энергосбытовая компания».

КЫЗЫЛ ЯЛАНДА ТАРИХ ЯШИ

Салаларыбыз тарихларының байлыгы, аларның шанлы үткәннәре, күренекле шәхесләре, гасырлар тирәнлеге белән генә бәһаләнми икән шул әле. Чистай районының Кызыл Ялан авылында булганнан соң, күңелдә күптәннән бөреләнгән шул фикер тагы да ныгый, көчәя төште. Ул сәфәребезне изге дип олылау һич тә арттыру галәмәте булып тоелмастыр. Беренчедән, җомга көн иде ул, икенчедән, авыл тарихына багышланган саллы китапны халыкка тәкъдим итү тантаналарында катнашу максатыннан юлга кузгалдык без. Халык санын алу кампаниясе башланып киткән 15 октябрьнең милләтебез язмышында ачы фаҗигаләре, тиңсез югалтулары белән күңелләребездә мәңге саклаучы Хәтер көне булуын да искәртү урынлы булыр. Юлдашларым – китап авторы, язучы Фидаил Мәҗитов, китапны чыгаруда ифрат зур ярдәм күрсәткән һәм моннан өч дистә ел элек яшәүдән туктаган туган авылы Тубылгыны тернәкләндереп җибәрү мәшәкатьләре белән җан атып йөрүче Рәфыйк Йосыпов һәм аның классташы Гөлчәчәк Җиһаншина.

Борынгы Татар Талкышы авылыннан күченүчеләр тарафыннан 1928–1929 елларда гына нигезләнүенә карамастан, Кызыл Яланның тарихи үткәне ерак гасырларга барып тоташа. Соңгы елларда тарихчылар, татар генеалогиясенә нигезләнеп, борынгы Гәрәй мирза нәселенең милләтебезгә бик күп күренекле шәхесләрне, шул исәптән әдәбиятыбыз классигы Фатыйх Әмирханны биргәнен исбатладылар. Проект авторлары нигезләп раслаганча, әлеге шанлы һәм затлы нәсел дәвамчыларының Кызыл Ялан да гомер кичерүләре мәгълүм.

Бер гасырга да тулмаган, кыска гына тарихы булган авыл аерата күренекле шәхесләре белән данлыклы. Бөек Ватан сугышында Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган Габбас Гыйниятуллин Кызыл Яланда яшәгән һәм вафатыннан соң авыл зиратында җирләнгән. Авылның үзәк урамы һәм мәдәният йорты каршындагы мәйдан каһарман шәхес исемен йөртә. Һава десанты дивизиясендә сугышкан, тыныч тормышта колхоз рәисе булган Ленин ордены кавалеры Салихҗан Мөэминовның балачагы һәм сугыштан соңгы еллары шулай ук шушы данлыклы авылга турыдан-туры бәйле. Балачак еллары Кызыл Яланда үткән хәрби диңгез фәннәре докторы, 1 нче ранг капитаны Усман Гайнетдинов сугыш вакытында «М-13» классындагы су асты көймәсенең командиры була. Батырлыклары өчен Кызыл Байрак, II дәрәҗә Ватан сугышы һәм өч мәртәбә Кызыл Йолдыз орденнары белән бүләкләнгән каһарман шәхес ул. 1934 елда Кызыл Ялан авылында туган ТАССРның атказанган механизаторы, Чистай каласының һәм районының мактаулы гражданы, Ленин, Октябрь революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары кавалеры, данлыклы механизатор Равил Мирсәяпов та – бөтен республика күләмендә танылган шәхесләребездән. Алдынгы сыер савучы, Хезмәт Кызыл Байрагы һәм Халыклар дуслыгы орденнары кавалеры Рәшидә Ситдыйк кызы Хафизова белән дә авылдашлары хаклы рәвештә горурлана. Китапны язуда башлап йөрүче якын туганнары – 1980–2001 елларда «Түбән Кама «Нефтехим» җәмгыяте генераль директоры урынбасары вазыйфасын башкарган Татарстанның атказанган икътисадчысы Әнвәр Вафа улы белән төрле җитәкче эшләрдә хезмәт куйган Әхәт Ситдыйк улы Хафизовлар икесе дә – Кызыл Ялан авылы тарихында лаеклы урын алып торучы мөхтәрәм затлар.

Әлбәттә, тагын бер легендар шәхес, Әхәтнең абыйсы, полк командиры вазыйфасында отставкага чыккан полковник Ильяс Хафизов турында күләмлерәк язма бирү тәгаен урынсыз тоелмас. 1973 елда СССР Эчке эшләр министрлыгының Орджоникидзедагы училищесын һәм 1989 елда М.В. Фрунзе исемендәге академияне тәмамлаган милләттәшебез авыр сынауларга бай булган хәрби хезмәт юлы үтә. Аның Әфганстанда бер үтә серле операцияне башкарып чыгу белән уңышлы командалык итүе аерым игътибарга лаек. Командование куйган бурыч – америкалылар әфган мөһаҗирләренә куя торган «Стингер» зенит-ракета комплексын кулга төшерү. Моның өчен Ильяс Хафизов Алтын Йолдызга лаек булуына карамастан, нибары Кызыл Йолдыз ордены белән генә бүләкләнә.

Кызыл Яланнан Бөек Ватан сугышында 130 ир-ат катнашып, шуларның 48е яу кырында ятып калган. Архив документларына нигезләнеп, китапта расланганча, авылдан сугышка киткәннәрнең 13е командирлар булып хезмәт иткән.

Бу чараның беренче өлеше Кызыл Ялан авылы мәчетендә үтү һич тә гайре табигый хәл түгел. Чөнки 2019 елның 29 ноябрендә, җомга көнне, нәкъ биредә авыл аксакаллары, Әнвәр һәм Әхәт Хафизовлар, Чаллыдан кайткан Рәфыйк Йосыпов белән язучы Фидаил Мәҗитов җыелып сөйләшеп, киңәшләшеп, китап язуны башларга килешкәннәр. Шунысы аерата әһәмиятле: күркәм яңа мәчет янәшәсендә генә, әле 1848 елда ук Татар Талкышы авылында төзелгән һәм 1929 елда Кызыл Яланга күчереп салынган, хәтта коммунистлар вакытында да манарасы саклап калынган тарихи мәчет тә авылга ислам нуры иңдереп утыра. Борынгы бу мәчетнең татар халкының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре исемлегенә кертелгән булуына да аерым игътибар юнәлтү мөһим.

Чистай районы имам-мөхтәсибе Мөхәммәд хәзрәт Кыямовның шәхсән үзе катнашында һәм аның фатыйхасы, вәгазе белән башланып киткән чарада китапны дөньяга тудыручылар бу изге эшнең ничек тормышка ашырылуын сөйләделәр. Аннан инде, Әнвәр һәм Әхәт Хафизовлар чарада катнашучы авылдашларына «Кызыл Ялан авылы тарихы» китапларын бүләк иттеләр. Күркәм чараның икенче өлеше Чистай каласының «Ислам мәдәни үзәге»ндә үтте.

Рәис ЗАРИПОВ

Олы юл насыйп булсын

Бердәмлеккә, татулыкка ни җитә! Казан Ратушасында «Шәрык базары» I Халыкара төрки эстрада фестиваленең ачылу тантанасында яңгыраган төп фикер әнә шул булды.

– Фестивальне олы, уңышлы юлга чыгарып җибәрергә насыйп булсын. Күпмилләтле республикабызның халкы, Россиянең төрле төбәкләрендә һәм чит илләрдә яшәүче татарлар гына түгел, башка милләт вәкилләре дә бу фестивальне үзенеке итеп, кирәк икәнен тоеп алырлар дип ышанам. Мондый чаралар безнең халыкларны берләштерүгә йөз тота. Тынычлык, татулык кына дөньяны, дәүләтне берләштерә, – диде ачылу тантанасында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин.

Фәрит Мөхәммәтшин фестивальдә катнашучыларга Президент Рөстәм Миңнехановның хәер-фатихасын да җиткерде.

«Фестивальнең республикада Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елында башлануы символик мәгънәгә ия. Төрки дөнья халыкларының этномәдәни традицияләре һәрвакыт үзенчәлекле күренеш буларак кабул ителде. «Шәрык базары» әһәмиятле мәдәни вакыйга булып, халыклар арасындагы элемтәләрне алга таба ныгытуга ярдәм итәр дип өметләнәм», – диелә сәламләү хатында.

Фестиваль милләтара һәм дәүләтара мәдәни багланышларны ныгыту, төрки халыклар эстрадасын үстерү максатыннан үткәрелә. Проект авторы һәм җитәкчесе, Рәшит Ваһапов исемендәге Татар мәдәнияте фонды директоры Рифат Фәттахов әйтүенчә, фестивальнең нәкъ менә Казанда башланып китүе табигый, чөнки Казан элек-электән Шәрык дөньясының мәдәни-мәгърифәти үзәге булган.

– Бу – тарихи вакыйга. Без бүген зур масштаблы проектка нигез салабыз. Казан Шәрык дөньясын Европа цивилизациясе белән тоташтырып торучы күпер ролен үтәгән. Безнең фестиваль дә үзенең нурларын әлеге юнәлеш буенча яктыртыр дип өметләнәбез, – диде ул.

Гала-концерт исә 2022 елның җәендә булыр дип көтелә.

tatarstan.ru

bolgarradio.com

ТАМАШАЧЫ ҮЗЕ САЙЛАДЫ

«БОЛГАР РАДИОСЫ»НЫҢ IX МИЛЛИ МУЗЫКАЛЬ ПРЕМИЯСЕ БӘЙГЕСЕНЕҢ ҖИҢҮЧЕЛӘРЕ БИЛГЕЛЕ!

Әлеге олы вакыйгага әзерлек ел дәвамында барды, халык иң яхшы, иң зәвыклы җырларны үзе сайлады. 11 декабрьдә узган бүләкләү тантанасын тамашачылар быел да туры трансляциядә күзәтә алды.

Милли премия бары тик лаеклы җырчыларга гына тапшырыла. Әлеге бүләккә «Кайнар хит» тапшыруы җиңүчеләре һәм «Болгар радиосы» тыңлаучылары фикеренә таянып сайланган иҗат әһелләре лаек була. Радиотыңлаучылар, тамашачылар куйган «лайк»лар, фикерләр, смс-хәбәрләр, шалтыратулар – җиңүчеләрне сайлаганда боларның барысы да исәпкә алынды. «Болгар радиосы» радиотыңлаучыларыбыз фикеренә таянып, җырларның «иң-иң»нәрен генә сайлый. Легендар җырчыларның иҗатын саклау һәм яктырту белән беррәттән, яшь җырчыларны танытуга да үз өлешен кертә.

«Болгар радиосы» Милли музыкаль премиясенең максаты – халык күңелендә үз урынын тапкан җырчыларны һәм җырларны барлап, алтын фондка кертү. IX Милли музыкаль премиясенең авторларга да тапшырылуы шулай ук үзенчәлекле матур традициягә әверелде.

Тантананы алыштыргысыз Илфар Кәримов, Рөстәм Гайзуллин һәм кыска вакыт эчендә күпләрнең мәхәббәтен яулап өлгергән «Иртәнге чәй», «Кайнар хит» тапшыруларының алып баручысы Эльвира Вилдан алып барды.

«Кайнар хит» тапшыруында җиңеп, «Тамашачы сайлавы» номинациясенә Ләйсән Мәхмүтова, Мурат Гайсин, Гөлнара Тимерҗанова, Азалия Зиннәт, Фәридә – Алсу дуэты, Гөлшат Имамиева, Лилия Муллагалиева, Азат Абитов, Рәнис Габбазов лаек булды.

«Кайнар хит» җиңүчеләреннән кала, ел дәвамында «Болгар радиосы»нда еш соралган һәм халык күңеленә кергән җырлар да «Алтын йолдыз» сыны белән бүләкләнде.

- Фирдүс Тямаев – «ЕЛ ҖЫРЧЫСЫ»
- Винарис Ильегет – «ИҢ ХИСЛЕ ҖЫРЧЫ»
- Зөфәр Хәйретдинов – «ЙӨРӘКЛӘРГӘ ҮТЕП КЕРГӘН ҖЫР»
- Ришат Фазлыйәхмәтов – «ИҢ РОМАНТИК ҖЫРЧЫ»
- Винера Ганиева – «ХАЛЫК МӘХӘББӘТЕ»
- Филүс Каһиров – «ХАЛЫКЧАН ҖЫРЧЫ»
- Ландыш Нигъмәтҗанова – «КАБАТЛАНМАС ТАВЫШ»
- Алсу һәм Азат Фазлыевлар – «ИҢ ХАЛЫКЧАН ДУЭТ»
- Гүзәлия – «ХАЛЫК КҮҢЕЛЕНӘ КЕРГӘН ҖЫР»
- Миңгол Галиев – «ТАТАР ЭСТРАДАСЫ ЛЕГЕНДАСЫ»
- Раяз Фасыйхов – «ИҢ ЛИРИК ҖЫР»
- Анастасия Макарова – «ИҢ ЭЗЛӘНҮЧӘН ҖЫРЧЫ»
- Гүзәл Идрисова – «ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ МОҢ»
- Рамилә һәм Рамил Хәйретдиновлар – «ИҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ ДУЭТ»
- Роман Плеханов – «ЯҢА ИСЕМ»
- Зөлфирә һәм Алмаз Мирзаяновлар – «ЕЛНЫҢ ГАИЛӘ ДУЭТЫ»
- Эльмира Кәлимуллина – «ИҢ ЗӘВЫКЛЫ ҖЫРЧЫ»
- Салават Миңнеханов һәм Гүзәлем – «ИҢ КРЕАТИВ ДУЭТ»
- Зинира һәм Ризат Рамазановлар – «ИҢ РОМАНТИК ДУЭТ»
- Илсөя Бәдретдинова – «ИҢ ЗАМАНЧА ҖЫРЧЫ»
- Ришат Төхвәтуллин – «ИҢ МОҢЛЫ ҖЫРЧЫ»

Ел саен бәйгедә «Татар эстрадасы легендасы» номинациясендә олуг җырчыларыбыз бүләкләнә. Алдагы елларда әлеге номинациядә Хәмдүнә Тимергалиева, Флера Сөләйманова, Рафаэль Ильясов, Мәсгут Имашев кебек олпат шәхесләребез олыланган иде. Быел Татарстанның халык артисты, күптән түгел 80 яшен тутырган Миңгол Галиев хөрмәткә лаек булды.

Туры трансляция барышында IPHONE 12 иясе билгеләнде! Ай дәвамында 5522 номерына МИЛЛИ сүзе белән смс-хәбәрләр кабул иттек. Трансляция барышында очраклы бер номер сайлап алынды. Телефонны Башкортстанның Зианчура районында яшәүче Флорида исемле ханым отты.

Белми калмагыз!

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»ГА ЯЗЫЛУЧЫГА – МИНИ-ТРАКТОР

БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН ТЕЛЕФОН: 8-917-927-00-40

БҮЛӘКНЕ АЛУ ШАРТЛАРЫ

1 2022 елның беренче яртыеллыгына 6 айга «Ватаным Татарстан» газетасына язылырга.

2 Язылу квитанциясен безгә җибәрергә: «Ватсап» (89179270040) яки почта аша (420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт, «ВТ» газетасы редакциясе), яки электрон адреска (info@vatantat.ru).

Җиңүче җирәбә юлы белән ачыкланачак. Квитанцияләр 2022 елның 16 гыйнварына кадәр кабул ителә, җирәбә 20 гыйнвар көнне үткәреләчәк.

Акцияне оештыручы: «Ватаным Татарстан» газетасы ДБУ, акцияне уздыру вакыты 2021 елның 1 ноябреннән 2022 елның 15 февраленә кадәр. Тулырак мәгълүмат vatantat.ru сайтында.

УРАЛЕЦ ТОРГОВЫЙ ДОМ МЫ ПРОДАЁМ НАДЁЖНОСТЬ

АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕСЕ – «УРАЛЕЦ» СӘҮДӘ ЙОРТЫ

- ✓ мини-тракторлар;
- ✓ барлык төр тракторлар өчен запас частьлар;
- ✓ җир эшкәртү, чәчү, җыйнау өчен асылмалы җиһазлар.

Казан ш., Мамадыш тракты, 35А; Чаллы ш., Казан проспекты, 252/1; Әлмәт ш., Советская урамы, 42А.

ТЕЛЕФОННАР: 8-927-465-12-94, 8-987-931-55-50

ГАЗЕТАГА ЯЗЫЛУ ЫСУЛЛАРЫ



1 ПОЧТА БҮЛЕКЧӘЛӘРЕНДӘ

2 ОНЛАЙН: **vatantat.ru сайтындагы сылтама аша газетага язылу бик уңайлы һәм тиз. Программа үзе адымлап алып бара.**

Әлеге QR-код ярдәмендә телефон аша газетага язылырга һәм акча түләргә мөмкин.

Сөенечле хәбәр!

2022 елның беренче яртыеллыгы өчен 6 айга язылу бәяләре

П2435 атнага бер, җомга килә — ~~465 сум~~ **404,04 сум**

П2409 Сишәмбе, чәршәмбе, җомга, шимбә килә — ~~1000,92 сум~~ **859,08 сум**

6–16 декабрь көннәрендә ташламалы бәяләр!

Реклама 16+

bars-media.ru

«ЯҢА ЙОЛДЫЗ»

ПРОЕКТНЫҢ ИКЕНЧЕ СЕЗОНЫНА ЙОМГАК ЯСАЛДЫ

«Яңа йолдыз» телевизион вокал проектының икенче сезоны тәмамланды. Татар эстрадасының яңа йолдызы дип аталу хокукына кем ия булды?

«Яңа йолдыз» проектының икенче сезоны май аенда башланып киткән иде. Конкурста Россиянең төрле төбәкләрендә яшәүче 18 яшьтән 35 яшькә кадәр булган һәр кеше катнаша алды. Талантлы яшьләрне тамашачыга күрсәтү, зур сәхнәгә күтәрү максатында үткәрелүче проектка быел 600ләп гариза килгән. Бу узган ел белән чагыштырганда 2 тапкыр күбрәк. Гариза бирүчеләр арасыннан сайланган 50 кеше җәй көне Иннополис шәһәрендә узган кастингта катнашты. Шулардан 22 талантлы башкаручы сайланып алынды. Алар, 3 командага бүленеп, 3 ай дәвамында остазлары – Алинә Шәрипҗанова, Алсу Әбелханова һәм Филүс Каһиров белән шөгыльләнделәр. Вокал, актерлык осталыгы һәм башка юнәлешләр буенча мастер-класслар үттеләр.

Финалга барлыгы 7 катнашучы узды: Самат Нургалиев, Аида Ибракова, Илшат Мөхәммәтҗанов, Алия Бәдретдинова, Майя Сайфуллина, Илнар Шәрәфетдинов һәм «Караш» төркеме. «Сәйдәш» мәдәни үзәгендә узган гала-концертта финалга узган яшь башкаручылар татар эстрадасының йолдызлары – Резедә Шәрәфиева, Ришат Фазлыйәхмәтов, Раяз Фасыйхов, Чулпан Йосыпова, Рифат Зарипов, «Ямьле» төркеме һәм Лилия Хәйруллина белән дуэт башкарды.

«Монда ялгышу мөмкин түгел иде»

– Татар телендә җырлый торган, татар телен, сәнгатен ярата торган яшь җырчылар килү мине бик куандыра. Әлбәттә, камиллекнең чиге юк. Тик араларында иң яхшылары сайланды. Монда ялгышу мөмкин түгел иде, – диде «Яңа йолдыз» проектының жюри әгъзасы, Татарстанның халык язучысы Зөлфәт Хәким.

Проект кысасында Алсу Әбелхановaның төркеме иң көчлесе санала. Ни өчен дигәндә, Филүс Каһиров белән Алинә Шәрипҗанова төркемнәреннән финалга икешәр катнашучы үткән булса, Алсу Әбелханова төркемендә – 3 финалист. Концерт башланганчы җырчы белән бераз аралашып алдык.

– Катнашучыларның барысы да бик талантлы, креатив. Энергияләре ташып тора, татар җырына, эстрадага нинди дә булса яңалык кертергә тырышалар. Мин үз чиратымда аларга бернинди киртәләр куймыйча, ярдәм итәргә, иҗатка булган карашларын, теләкләрен тормышка ашырырга тырыштым, – дип сөйләде Алсу. – Безнең тамашачы бит ул бик сайланучан. Монда матур тавыш кына, талант кына җитми, үзеңне сәхнәдә тота белү, үз-үзеңә ышану һәм бик күп тырышлык кирәк. Әлбәттә, барысы да тәҗрибә белән килә. Тик талантың бар икән, гел үз өстеңдә эшләргә кирәк. Менә шул вакытта син йолдыз була аласың, – диде ул.

Шулай итеп, «Яңа йолдыз» проектының икенче сезоны җиңүчесе булып «Караш» төркеме табылды. Алар «Барс Рекордс» продюсерлык үзәге белән контракт төзү, җырларын профессиональ яздыру, клип төшерү һәм аны «ТМТВ» телеканалына ротациягә бирү мөмкинлегенә ия булдылар. Шулай ук яшь җырчылар «Татар җыры – 2021» фестивалендә катнашачак.

«Караш»ка караш ныграк булды»

Җиңүчене нинди критерийлар буенча сайлаганнар икән соң? Бу сорауга жюри әгъзалары җавап бирде.

Татарстанның атказанган артисты Эльмира Кәлимуллина беренче чиратта җырлауга каравын әйтте.

– Әлеге конкурста «Караш» төркеме искиткеч үсеш күрсәтте. Бер-берсе белән сәхнәдә эшләүләре дә югары дәрәҗәдә булды, – диде ул.

Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты Айдар Галимов әйтүенчә, башка финалистлар арасында да сайлап алырдай егетләр, кызлар булган.

– Кемдер үсте, кемдер югалып калды, кемдер бөтенләй китте, ә «Караш» төркеме беренче көннән бүгенгә кадәр зур үсеш, тырышлык һәм омтылыш күрсәтте. Башка финалистлар арасында да сайлап алырдай егетләр, кызлар бар иде. Зур, киеренке бәхәс барды, әмма шулай да, бер тавыш белән «Караш»ка караш ныграк булды, – дип сөйләде ул.

«Караш» төркеменең үзе өчен исә бу күптән көтеп алынган һәм бик шатлыклы вакыйга булды.

– Безнең төркемгә быел 3 яшь кенә тула. Никадәр тырышлык куйганыбызны үзебез генә беләбез. Әлегә безнең өчен бик үк җиңел вакыт түгел иде. Өмет чаткысы бүләк иткәнегез өчен чын күңелдән зур рәхмәт! – диде егетләр.

Ләйсән САФИНА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7387 данә
Гомуми тираж – 17167 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 382

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+